**Муниципаль хезмәт турында**
**Татарстан Республикасы**
**кодексы**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 30 маенда
кабул ителде

## 1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

### 1 статья. **Әлеге Кодексны җайга салу предметы**

1. Әлеге Кодекс Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне оештыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала, шулай ук федераль законнар нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт узу шартларын һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хокукый хәлен (статусын) билгели.

2. Әлеге Кодекс белән җирле үзидарә депутатларының, сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарә сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең даими нигездә эшләүче һәм юридик затлар булучы сайлау комиссияләренең (алга таба – муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре) хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисенең, шулай ук, әгәр муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары һәм аудиторлары вазыйфалары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив хокукый акты белән муниципаль вазыйфаларга кертелгән булса, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасарының һәм аудиторларының статусын билгеләми, чөнки күрсәтелгән затлар (алга таба – муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар) муниципаль хезмәткәрләр булып тормый.

### 2 статья. **Муниципаль хезмәт**

1. Муниципаль хезмәт – гражданнарның хезмәт шартнамәсе (контракты) төзү юлы белән биләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларында даими нигездә башкарылучы профессиональ эшчәнлек.

2. Муниципаль берәмлек муниципаль хезмәткәр өчен эшкә яллаучы булып тора, аның исеменнән эшкә яллаучы вәкаләтләрен эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) гамәлгә ашыра.

3. Эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиле муниципаль берәмлек башлыгы, җирле үзидарә органы җитәкчесе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе яисә эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) вазыйфаларын башкарырга вәкаләтле бүтән зат булырга мөмкин.

3 статья. **Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең хокукый нигезләре**

1. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең хокукый нигезләрен Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон) һәм башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Кодекс, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль берәмлекләр уставлары, гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарлар һәм бүтән муниципаль хокукый актлар тәшкил итә.

2. Муниципаль хезмәткәрләргә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган үзенчәлекләре белән хезмәткә кагылышлы законнарның гамәлдә булуы кагыла.

4 статья. **Муниципаль хезмәтнең төп принциплары**

Муниципаль хезмәтнең төп принциплары түбәндәгеләр:

1) кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең өстенлеге;

2) Россия Федерациясе дәүләт телен белүче гражданнарның муниципаль хезмәткә бертигез дәрәҗәдә алынулары һәм, җенесенә, расасына, милләтенә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, җәмәгать берләшмәләрендә торуы-тормавына, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең профессиональ һәм эшлекле сыйфатларына бәйле булмаган башка хәлләргә бәйсез рәвештә муниципаль хезмәт узуның бертигез шартлары;

3) муниципаль хезмәткәрләрнең профессиональлеге һәм компетентлыгы;

4) муниципаль хезмәтнең тотрыклылыгы;

5) муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалана алу;

6) җәмәгать берләшмәләре һәм гражданнар белән үзара хезмәттәшлек;

7) муниципаль хезмәткә карата төп таләпләрнең бердәйлеге, шулай ук муниципаль хезмәт узганда тарихи һәм бүтән җирле традицияләрне исәпкә алу;

8) муниципаль хезмәткәрләрнең хокукый һәм социаль яклануы;

9) муниципаль хезмәткәрләрнең үз вазыйфаи бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыгы;

10) муниципаль хезмәтнең партиягә карамавы.

5 статья. **Россия Федерациясе муниципаль хезмәтенең һәм дәүләт граждан хезмәтенең үзара бәйләнеше**

Муниципаль хезмәтнең һәм Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең (алга таба – дәүләт граждан хезмәте) үзара бәйләнеше түбәндәгеләр аша тәэмин ителә:

1) муниципаль хезмәт вазыйфаларына һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына төп квалификация таләпләренең бердәйлеге;

2) муниципаль хезмәт һәм дәүләт граждан хезмәте узганда чикләүләрнең һәм бурычларның бердәйлеге;

3) муниципаль хезмәткәрләрне һәм дәүләт граждан хезмәткәрләрен әзерләүгә, яңадан әзерләүгә һәм аларның квалификацияләрен күтәрүгә карата таләпләрнең бердәйлеге;

4) дәүләт граждан хезмәте стажын санаганда муниципаль хезмәт стажын исәпкә алу һәм муниципаль хезмәт стажын санаганда дәүләт граждан хезмәте стажын исәпкә алу;

5) муниципаль хезмәткәрләрнең һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүнең төп шартларының һәм социаль гарантияләренең туры килүе;

6) муниципаль хезмәт узган гражданнарның, һәм дәүләт граждан хезмәте узган гражданнарның дәүләт пенсиясе белән тәэмин ителү буенча төп шартларның туры килүе.

2 бүлек. **Муниципаль хезмәт вазыйфалары**

6 статья. **Муниципаль хезмәт вазыйфалары, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры**

1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы – муниципаль берәмлек уставы нигезендә төзелә торган җирле үзидарә органындагы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратындагы вазыйфа, аңа җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе яисә муниципаль вазыйфаны биләүче зат вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итү бурычларының билгеләнгән даирәсе керә.

2. Муниципаль хезмәт вазыйфалары Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә (әлеге Кодекска 1 нче кушымта).

Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры җирле үзидарә органнары, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре, вазыйфаларның төркемнәре, тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алып билгеләнгән функциональ билгеләре буенча классификацияләнгән муниципаль хезмәт вазыйфалары атамалары исемлегеннән гыйбарәт.

3. Җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратының штат расписаниесен төзегәндә һәм раслаганда Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрында каралган муниципаль хезмәт вазыйфалары атамалары кулланыла.

4. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын ике төрле атау түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

1) җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары әлеге органның структур бүлекчәсе җитәкчесе булып торса;

2) җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары әлеге органның структур бүлекчәсендә бүлекчә җитәкчесе булып торса.

5. Җирле үзидарәнең башка органы (башка структур бүлекчәсе) җитәкчесе вазыйфасы атамасы муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) башка муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

6. Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары, аудиторлары вазыйфалары муниципаль вазыйфаларга кертелгән очракта, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив хокукый акты белән күрсәтелгән вазыйфалар муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелми.

7 статья. **Муниципаль хезмәт вазыйфаларын классификацияләү, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте**

1. Муниципаль хезмәт вазыйфалары түбәндәге төркемнәргә бүленә:

1) муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары;

2) муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары;

3) муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары;

4) муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары ;

5) муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары.

2. Әлеге Кодекста Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте дигәндә, муниципаль хезмәтнең һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазыйфаларына куела торган квалификация таләпләренә бәйле рәвештә шушы вазыйфаларның туры килүе аңлашыла.

3. Җирле үзидарә органнарында, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре аппаратларында муниципаль хезмәт вазыйфаларының туры килүе Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үзәк аппаратларындагы вазыйфаларның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрында каралган исемлеге буенча билгеләнә.

4. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте әлеге Кодекска 2 нче кушымта белән билгеләнде.

5. Әлеге Кодекста каралмаган муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте әлеге Кодекска тиешле үзгәрешләр кертү нигезендә билгеләнә.

8 статья. **Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре**

1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт (дәүләт хезмәте) стажына яисә белгечлеге буенча эш стажына, вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәренә һәм күнекмәләренә карата куела.

2. Квалификация таләпләре муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән үрнәк квалификация таләпләре нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге үрнәк квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган югары һөнәри белем булу – вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре өчен; эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган югары яисә урта һөнәри белем булу – вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эш стажына карата:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча – муниципаль хезмәтнең баш яисә әйдәүче вазыйфаларында кимендә ике ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек буенча кимендә биш ел эш стажы булу;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары буенча – муниципаль хезмәтнең әйдәүче яисә өлкән вазыйфаларында кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек буенча кимендә ике ел эш стажы булу;

муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары буенча – муниципаль хезмәтнең өлкән яисә кече вазыйфаларында кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек буенча кимендә ике ел эш стажы булу;

3) һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата:

Россия Федерациясе Конституциясен, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны (алга таба – «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон), «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законны, Татарстан Республикасы Конституциясен, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, әлеге Кодексны, тиешле муниципаль берәмлек уставын, муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә карата башка норматив хокукый актларны, хезмәтне саклауның норматив таләпләрен һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, тиешле муниципаль органда эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен белү – вазыйфаларның барлык төркемнәре өчен;

хезмәткә кагылышлы мәгълүмат белән эшләү, эшләр башкару һәм эшлекле аралашу нигезләре өлкәсендә белемнәр һәм күнекмәләр – югары, баш, әйдәүче һәм өлкән төркем вазыйфалары өчен.

4. Өлкән һәм кече төркем муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эш стажына карата квалификация таләпләре билгеләнми.

5. Муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә әлеге статья максатларында шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрнең дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларындагы һәм шуларга тиңләштерелгән хәрби һәм хокук саклау хезмәте вазыйфаларындагы эш стажы исәпкә алына.

6. Муниципаль район (шәһәр округы) җирле администрациясенең контракт буенча билгеләнеп куела торган башлыгы вазыйфасына кандидатларга өстәмә таләп итеп кимендә биш ел идарә итү эшчәнлеге тәҗрибәсе булу билгеләнә. Әлеге өлештә идарә итү эшчәнлеге дигәндә, оешма, дәүләт органы, муниципаль орган җитәкчесе, җитәкче урынбасары вазыйфаларында, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларында эшләү аңлашыла. Җирле администрациянең контракт буенча билгеләнеп куела торган башлыгы вазыйфасына кандидатларга өстәмә таләпләр муниципаль берәмлек уставы белән дә билгеләнергә мөмкин.

## 9 статья. **Муниципаль хезмәткәрләрнең класс чиннары**

1. Класс чиннары муниципаль хезмәткәрләргә бирелә һәм муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри әзерлек дәрәҗәсенең муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүен күрсәтә.

2. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә түбәндәге класс чиннары бирелә:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфаларын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 нче класслы гамәли муниципаль киңәшче;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфаларын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 нче класслы муниципаль киңәшче;

муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфаларын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 нче класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе;

муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфаларын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 нче класслы муниципаль хезмәт референты;

муниципаль хезмәтнең кече вазыйфаларын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 нче класслы муниципаль хезмәт секретаре.

3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын югарыда күрсәтелгән төркемнәргә кертү Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 10 статья. **Муниципаль хезмәткәрләргә класс чиннарын бирү һәм муниципаль хезмәткәрләрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфаларына күчергәндә һәм муниципаль хезмәттән җибәргәндә класс чиннарын саклап калу тәртибе**

1. Муниципаль хезмәткәрләргә класс чиннары, моннан алдагы класс чинында булуның билгеләнгән дәвамлылыгын исәпкә алып, муниципаль хезмәт вазыйфалары төркеме чикләрендә биләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфасы нигезендә эзлекле рәвештә бирелә.

2. Класс чины башлангыч яисә чираттагы булырга мөмкин.

3. Билгеле бер төркемдәге муниципаль хезмәт вазыйфасына беренче мәртәбә билгеләнеп куела торган муниципаль хезмәткәрләргә 3 нче класслы класс чины бирелә.

4. Федераль дәүләт граждан хезмәте класс чинына, дипломатик рангка, хәрби яисә махсус дәрәҗәгә, Татарстан Республикасы яисә Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәтенең класс чинына, муниципаль хезмәтнең квалификация разрядына ия булган граждан муниципаль хезмәткә урнашканда, аңа башлангыч класс чины муниципаль хезмәт вазыйфалары төркеме чикләрендә ул били торган вазыйфа нигезендә бирелә.

5. Муниципаль хезмәткәргә әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә класс чины бирү максатларында муниципаль хезмәтнең моңа кадәр билгеләнгән квалификация разрядлары һәм класс чиннары нисбәте, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте класс чиннары һәм федераль дәүләт граждан хезмәте, Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәте класс чиннары нисбәте, шулай ук федераль дәүләт граждан хезмәте класс чиннары, дипломатик ранглар, хәрби һәм махсус дәрәҗәләр нисбәте кулланыла.

6. Әгәр, әлеге статьяның 5 өлешендә каралган вазыйфаларның, класс чиннарының һәм квалификация разрядларының нисбәтен исәпкә алып, әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә бирелә торган муниципаль хезмәтнең класс чины муниципаль хезмәткәрнең моңа кадәр булган федераль дәүләт граждан хезмәте класс чинынnан, дипломатик рангыннан, хәрби яисә махсус дәрәҗәсеннән, Татарстан Республикасы яисә Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәте класс чиныннан, муниципаль хезмәтнең квалификация разрядыннан түбәнрәк булса, муниципаль хезмәткәргә аның моңа кадәр булган федераль дәүләт граждан хезмәте класс чиныннан, дипломатик рангыннан, хәрби яисә махсус дәрәҗәсеннән, Татарстан Республикасы яисә Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәте класс чиныннан, муниципаль хезмәтнең квалификация разрядыннан түбәнрәк булмаган, әмма ул били торган муниципаль хезмәт вазыйфасы карый торган муниципаль хезмәт вазыйфалары төркеме чикләрендә 1 нче класслы класс чиныннан югарырак булмаган класс чины бирелә.

7. Муниципаль хезмәткәргә алга таба чираттагы класс чины бирелгәндә федераль дәүләт граждан хезмәтенең тиешле класс чинында, дипломатик рангта, хәрби яисә махсус дәрәҗәдә, Татарстан Республикасы яисә Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәте класс чинында, муниципаль хезмәтнең квалификация разрядында булу дәвамлылыгы исәпкә алына.

8. Муниципаль хезмәткәргә башлангыч класс чины сынауны уңышлы тәмамлаганнан соң бирелә, ә сынау билгеләнмәгән булса, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куйганнан соң өч ай узгач кына бирелә.

9. 2 нче һәм 3 нче классы муниципаль хезмәт секретаренең һәм референтының класс чиннарында булуларының минималь сроклары – бер ел, 2 нче һәм 3 нче классы муниципаль хезмәт киңәшчесенең һәм муниципаль киңәшченең – ике ел, 2 нче һәм 3 нче классы гамәли муниципаль киңәшченең бер ел тәшкил итә. 1 нче классы муниципаль хезмәт секретареның, референтының, киңәшчесенең,

муниципаль киңәшченең һәм гамәли муниципаль киңәшченең класс чиннарында булу сроклары билгеләнми. Күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрләрнең класс чиннарын күтәрү аларны тиешле төркем муниципаль хезмәтнең югарырак вазыйфаларына күчергәндә мөмкин.

10. Бирелгән класс чинында булу срогы ул бирелгән көннән исәпләнә.

11. Класс чины бирелү турында карар кабул ителгән көн класс чины бирелгән көн дип санала. Класс чины квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча бирелгән очракта, муниципаль хезмәткәр квалификация имтиханы биргән көн класс чины бирелгән көн дип санала.

12. Муниципаль хезмәткәргә чираттагы класс чины моннан алдагы класс чинында муниципаль хезмәт узу өчен билгеләнгән срок тәмамлангач, муниципаль хезмәткәр үз хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәгәндә һәм ул муниципаль хезмәткәргә бирелә торган класс чинына тигез яисә югарырак класс чины каралган муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгәндә бирелә.

13. Чираттагы класс чины дисциплинар җәза алган муниципаль хезмәткәрләргә, шулай ук үзләренә карата хезмәт тикшерүе уздырыла торган яисә җинаять эше кузгатылган муниципаль хезмәткәрләргә бирелми.

14. Муниципаль хезмәттәге аерым казанышлары өчен кызыксындыру чарасы буларак муниципаль хезмәткәргә класс чины түбәндәгечә бирелергә мөмкин:

1) тиешле класс чинында муниципаль хезмәт узу өчен әлеге статьяның 9 өлешендә билгеләнгән срок тәмамланганчы, әмма элек бирелгән класс чиныннан алты айдан да элгрәк булмаган вакытта, – муниципаль хезмәт вазыйфаларының бу төркемгә туры килә торган чираттагы класс чиныннан югарырак булмаган дәрәҗәдә;

2) муниципаль хезмәт вазыйфаларының биләнә торган вазыйфасына карый торган төркем чикләрендә класс чиннары бирелү эзлеклелеген сакламыйча бер дәрәҗәгә югарырак – 3 нче класслы класс чины булган муниципаль хезмәткәргә – 1 нче класслы чин, әмма ул тиешле класс чинының 3 нче классында муниципаль хезмәт узу өчен әлеге статьяның 9 өлешендә билгеләнгән сроктан да элгрәк була алмый.

15. Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәт вазыйфаларының элеккеге төркеме чикләрендә югарырак вазыйфага билгеләп куйганда аңа, әгәр әлеге статьяның 9 өлешендә билгеләнгән моннан алдагы класс чинында булу срогы узган булса, чираттагы класс чины бирелергә мөмкин.

16. Муниципаль хезмәткәрне элек ул биләгән муниципаль хезмәт вазыйфаларының югарырак төркеменә керә торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куйганда, күрсәтелгән хезмәткәргә әлеге Законның 9 статьясы нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының бу төркеме өчен башлангыч булган класс чины, әгәр бу класс чины муниципаль хезмәткәр ия булган класс чиныннан югарырак булса, бирелә. Мондый очракта класс чины эзлеклелекне үтәмичә һәм моннан алдагы класс чинында булу срогын исәпкә алмыйча бирелә.

17. Аерым бер вәкаләтләр срогына муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә, югары төркем муниципаль хезмәт вазыйфаларына керә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрдән тыш, класс чиннары квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча бирелә.

Квалификация имтиханы дәүләт граждан хезмәткәрләренә квалификация имтиханы тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

18. Муниципаль хезмәткәрләргә класс чиннары җирле үзидарәнең муниципаль берәмлек уставы яисә башка муниципаль хокукый акт белән вәкаләт бирелгән органы һәм (яисә) вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе күрсәтмәсе буенча бирелә.

19. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирелү турындагы күрсәтмәләрне кертү тәртибе һәм аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

20. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирелү турында карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, бер айдан да соңга калмыйча түбәндәгечә кабул ителергә тиеш:

1) квалификация имтиханы үткәрелгән көннән;

2) класс чины квалификация имтиханыннан башка бирелгәндә – барлык кирәкле документлар белән бергә, класс чины бирелү турында күрсәтмә класс чиннары бирергә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кертелгән көннән.

21. Муниципаль хезмәткәрләрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфаларына күчергәндә, шулай ук муниципаль хезмәттән җибәрелгәндә муниципаль хезмәткәргә моңа кадәр бирелгән класс чины сакланып кала. Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына билгеләп куйганда, аңа моңа кадәр бирелгән класс чины билгеләнгән тәртиптә чираттагы класс чины бирелгәнче сакланып кала.

22. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирелү турындагы белешмәләр муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшнамәсенә һәм хезмәт кенәгәсенә кертелә.

### 11 статья. **Муниципаль хезмәтнең класс чинын саклап калу яисә аннан мәхрүм итү**

1. Муниципаль хезмәткәр били торган муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәндә һәм муниципаль хезмәттән җибәрелгәндә (шул исәптән пенсиягә чыкканда), шулай ук яңадан муниципаль хезмәткә урнашканда элек бирелгән класс чины сакланып кала.

2. Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына билгеләп куйганда, аның элек бирелгән класс чины билгеләнгән тәртиптә чираттагы класс чины бирелгәнче сакланып кала.

3. Бирелгән класс чиныннан мәхрүм итү федераль законнар нигезендә суд карары белән башкарылырга мөмкин.

## 3 бүлек. **Муниципаль хезмәткәрнең хокукый хәле (статусы)**

### 12 статья. **Муниципаль хезмәткәр**

1. Җирле бюджет акчалары исәбеннән түләнә торган акчалата тулаем хезмәт хакы алып, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә

муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт вазыйфасы бурычларын башкаручы граждан муниципаль хезмәткәр була.

2. Җирле үзидарә органнары, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү вазыйфаларын башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазыйфасын биләми һәм муниципаль хезмәткәр булмый.

13 статья. **Муниципаль хезмәткәрнең төп хокуклары**

1. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль хезмәтнең үзе били торган вазыйфасы буенча хокукларын һәм бурычларын билгели торган документлар белән, вазыйфаи бурычларын үтәү сыйфатын бәяләү критерийлары һәм хезмәт буенча үсү шартлары белән танышырга;

2) вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле оештыру-техник шартлар белән тәэмин ителергә;

3) хезмәт өчен түләүгә һәм хезмәт законнары, муниципаль хезмәт турындагы законнар һәм хезмәт шартнамәсе (контракты) нигезендә башка түләүләргә;

4) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләүне, ял көннәре һәм эш көннәре булмаган бәйрәм көннәре, шулай ук ел саен түләүле отпусклар бирүне тәэмин итә торган ялга;

5) вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле мәгълүматны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә алырга, шулай ук җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү турында тәкъдимнәр кертергә;

6) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста үз инициативасы белән катнашырга;

7) муниципаль хокукый акт нигезендә җирле бюджет акчалары исәбеннән квалификациясен арттырырга;

8) үзенең персональ белешмәләренең яклануына;

9) үзенең шәхси эшнамәсендәге барлык материаллар, һөнәри эшчәнлеге турындагы бәяләүләр һәм башка документлар белән аларны шәхси эшнамәсенә керткәнче танышырга, шулай ук шәхси эшнамәсенә үзенең язма аңлатмаларын кушып бирергә;

10) һөнәр берлекләре булдыру хокукын да кертеп, үз хокукларын, социаль-икътисадый һәм һөнәри мәнфәгатьләрен яклау өчен берләшергә;

11) хезмәт законнары нигезендә индивидуаль хезмәт бәхәсләрен каратуына, муниципаль хезмәттәге үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, аларның бозылуы турында судка шикаять белдерүне дә кертеп, яклатуына;

12) Россия Федерациясе законнары нигезендә пенсия тәэминатына.

2. Муниципаль хезмәткәр, җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча биләүче муниципаль хезмәткәрдән тыш, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) алдан язмача хәбәр итеп, түләүле бүтән эш башкарырга хокуклы, әгәр дә бу мәнфәгатьләр конфликтын китереп чыгармаса һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда башкасы каралмаган булса.

14 статья. **Муниципаль хезмәткәрнең төп бурычлары**

1. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституциячел законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, муниципаль берәмлек уставын һәм бүтән муниципаль хокукый актларны үтәргә һәм аларның башкарылуын тәэмин итәргә;

2) вазыйфаи инструкция нигезендә вазыйфаи бурычларын үтәргә;

3) вазыйфаи бурычларын башкарганда гражданнарның һәм оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

4) җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында эчке хезмәт тәртибенең билгеләнгән кагыйдәләрен, вазыйфаи инструкцияне, хезмәттәге мәгълүмат белән эшләү тәртибен үтәргә;

5) вазыйфаи бурычларын тиешенчә үтәү өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен сакларга;

6) дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне, шулай ук вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә үзенә мәгълүм булган белешмәләрне, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә, намусына һәм абруена кагылышлы белешмәләрне фаш итмәскә;

7) дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне, шул исәптән вазыйфаи бурычларын үтәү өчен үзенә тапшырылган мөлкәтне сакларга;

8) үзе һәм гаилә әгъзалары турында Россия Федерациясе законнарында каралган белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә тапшырырга;

9) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу турында Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан көнне яисә чит ил гражданлыгын алу хакында чит ил гражданлыгын алган көнне яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) хәбәр итәргә;

10) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәргә, бурычларны башкарырга, тыюларны бозмаска;

11) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерерлек шәхси кызыксынуы турында турыдан-туры башлыгына язмача хәбәр итәргә һәм мондый конфликтны булдырмау чараларын күрергә.

2. Муниципаль хезмәткәр үзенә хокукка яраксыз рәвештә бирелгән йөкләмәне үтәргә хокуксыз. Муниципаль хезмәткәр фикере буенча тиешле җитәкчедән хокукка яраксыз йөкләмә алынганда, муниципаль хезмәткәр, әлеге йөкләмәнең хокукка яраксызлыгын нигезләп, аны үтәгәндә бозылырга мөмкин булган федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының, муниципаль хокукый актларның нигезләмәләрен күрсәтеп, үзенә йөкләмә биргән җитәкчегә язмача нигезләү тапшырырга тиеш. Җитәкче әлеге йөкләмәне язмача раслаган очракта, муниципаль хезмәткәр аны үтәүдән баш тартырга тиеш. Хокукка

яраксыз йөкләмә үтәлгән очракта, муниципаль хезмәткәр һәм бу йөкләмәне биргән җитәкче Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

15 статья. **Муниципаль хезмәткә бәйле чикләүләр**

1. Граждан түбәндәге очракларда муниципаль хезмәткә алына алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәттә була алмый:

1) үз көченә кергән суд карары белән эшкә яраксыз яки чикле рәвештә яраклы дип танылса;

2) үз көченә кергән суд хөкеме белән муниципаль хезмәт вазыйфасының вазыйфаи бурычларын үтәү мөмкинлеген калдырмый торган җәзага тартылса;

3) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачы гражданның вазыйфаи бурычлары яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычлары дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр белән бәйле булса, әлеге белешмәләр белән эшләүгә рөхсәт алуны рәсмиләштерү процедурасын үтүдән баш тартса;

4) муниципаль хезмәткә урнашуга яисә аны үтүгә комачауларлык һәм медицина учреждениесе бәяләмәсе белән расланган авыруы булса;

5) җирле администрацияне җитәкләүче муниципаль берәмлек башлыгы белән якын кардәшлектә яки үги туганлыкта (ата-анасы, ире (хатыны), балалары, абыйлары, апалары, шулай ук ир белән хатынның абыйлары, апалары, ата-аналары, балалары һәм балаларының ире (хатыны) булса, әгәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү әлеге вазыйфаи затка турыдан-туры буйсыну яисә аның контрольлегендә булу белән бәйле булганда, яисә муниципаль хезмәткәр белән, әгәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү әлеге муниципаль хезмәткәрләрнең бер-берсенә турыдан-туры буйсыну яисә бер-берсенең контрольлегендә булу белән бәйле булганда;

6) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылса, чит дәүләт гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнаша торган чит дәүләт гражданлыгы туктатылса, чит дәүләт гражданлыгын алса яки чит дәүләт гражданлыгына ия Россия Федерациясе гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашмый торган чит дәүләт территориясендә Россия Федерациясе гражданының яшәүгә рөхсәт яисә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алса;

7) чит дәүләт (чит дәүләтләрнең) гражданлыгы булса, муниципаль хезмәткәр чит дәүләт гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданы булып торган очраклардан тыш;

8) муниципаль хезмәткә урнашканда ялган документлар яисә күрәләтә ялган белешмәләр тапшырса;

9) муниципаль хезмәткә урнашканда «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда, «Коррупциягә каршылык турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – «Коррупциягә каршылык турында» Федераль закон) һәм башка федераль законнарда каралган

белешмәләрне тапшырмаса яисә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырса.

2. Граждан муниципаль берәмлек башлыгы белән якын кардәшлектә яки үги туганлыкта (ата-анасы, ире (хатыны), балалары, абыйлары, апалары, шулай ук ир белән хатынның абыйлары, апалары, ата-аналары, балалары) булса, җирле администрация башлыгы вазыйфасына контракт буенча билгеләп куела алмый, ә муниципаль хезмәткәр җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча били алмый.

3. Граждан 65 яше – муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән чик яше тулганнан соң муниципаль хезмәткә алына алмый.

16 статья. **Муниципаль хезмәткә бәйле тыюлар**

1. Муниципаль хезмәткәргә муниципаль хезмәт үтүгә бәйле түбәндәгеләр тыела:

1) коммерциячел оешма идарәсе органының әгъзасы булып торырга, әгәр федераль законнар белән башкасы каралмаган булса яисә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә аңа бу оешмага идарә итүдә катнашу йөкләнмәгән булса;

2) түбәндәге очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торырга:

а) Россия Федерациясенең дәүләт вазыйфасына йә Россия Федерациясе субъектының дәүләт вазыйфасына сайланса яисә билгеләп куелса, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләп куелса;

б) муниципаль вазыйфага сайланса яисә билгеләп куелса;

в) һөнәр берлеге органында, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органында түләүле сайланулы вазыйфага сайланса;

3) эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

4) үзе муниципаль хезмәт вазыйфасын били торган йә аңа турыдан-туры буйсынган яисә аның контрольлегендә булган җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә өченче затлар эшләре буенча ышанычлы зат яисә вәкил булырга, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса;

5) физик һәм юридик затлардан вазыйфаи дәрәҗәгә бәйле рәвештә яисә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата кызыксындыру, ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачулар, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләр) алырга. Муниципаль хезмәткәрнең протокол чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле алынган бүләкләре муниципаль милек булып таныла һәм, Россия Федерациясенең Гражданлык кодексында билгеләнгән очраклардан тыш, үзе муниципаль хезмәт вазыйфасын били торган җирле үзидарә органына, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә акт буенча тапшырыла;

6) физик һәм юридик затларның акчалары исәбеннән командировкаларга йөрергә, җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең

башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, сайлау комиссияләре белән, шулай ук чит илләрнең дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, халыкара һәм чит дәүләтләрнең коммерциячел булмаган оешмалары белән үзара килешүе нигезендә гамәлгә ашырыла торган командировкалардан тыш;

7) вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле булмаган максатларда матди-техник, финанс һәм башкалар белән тәэмин итү чараларыннан, башка муниципаль мөлкәттән файдаланырга;

8) үзенә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә мәгълүм булган федераль законнар нигезендә конфиденциаль характердагы белешмәләргә караган белешмәләрне яисә хезмәт мәгълүматын фаш итәргә яисә муниципаль хезмәткә бәйле булмаган максатларда файдаланырга;

9) җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе һәм аларның җитәкчеләре эшчәнлегенә карата халык алдында фикерләр әйтүгә, фикер йөртүләргә һәм бәя бирүгә ирек бирергә, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында, әгәр болар аның вазыйфаи бурычларына кермәсә;

10) муниципаль берәмлек башлыгының язмача рөхсәтеннән башка чит илләрнең, халыкара оешмаларның, шулай ук сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен (фәнни дәрәҗәләрдән тыш) алырга, әгәр күрсәтелгән оешмалар һәм берләшмәләр белән үзара эшләү аның вазыйфаи бурычларына керсә;

11) сайлау алды агитациясендә, шулай ук референдум мәсьәләләрен агитацияләгәндә вазыйфаи дәрәҗәсенең өстенлекләреннән файдаланырга;

12) вазыйфаи дәрәҗәсен сәяси партияләр, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләр мәнфәгатьләрендә файдаланырга, шулай ук халык алдында күрсәтелгән берләшмәләргә үзенең мөнәсәбәтен муниципаль хезмәткәр буларак белдерергә;

13) җирле үзидарә органнарында, башка муниципаль органнарда сәяси партияләр, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләр структураларын (һөнәр берлекләре, шулай ук ветераннар һәм иҗтимагый үзешчән сәнгатьнең башка органнарыннан тыш) төзергә яисә күрсәтелгән структураларны төзүдә ярдәм итәргә;

14) хезмәткә кагылышлы бәхәсләрне җайга салу максатларында вазыйфаи бурычларын үтәүне туктатырга;

15) идарә органнары, попечительлек яисә күзәтү советлары, чит дәүләтләрнең хөкүмәткә карамаган коммерциячел булмаган оешмаларының бүтән органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эш йөртүче структур бүлекчәләре составына керергә, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;

16) яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) язмача рөхсәтеннән башка бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит дәүләт оешмалары, чит дәүләт гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларның акчалары исәбеннән финанслана торган түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса.

2. Җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча биләүче муниципаль хезмәткәр, мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән гайре, түләүле бүтән эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуксыз. Мөгаллимлек, фәнни һәм

башка иҗат эшчәнлеге, Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит дәүләт оешмалары, чит дәүләт гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларның акчалары исәбеннән генә финанслана алмый. Җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча биләүче муниципаль хезмәткәр, Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яисә күзәтү советлары, чит дәүләтләрнең хөкүмәткә карамаган коммерциячел булмаган оешмаларының бүтән органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эш йөртүче структур бүлекчәләре составына керергә хокуксыз.

3. Граждан, муниципаль хезмәттән җибәрелгәч, үзенә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә мәгълүм булган конфиденциаль характердагы белешмәләрне яисә хезмәт мәгълүматын фаш итәргә яисә оешмалар йә физик затлар мәнфәгатьләрендә файдаланырга хокуксыз.

4. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән вазыйфаны биләгән граждан, бу муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына оешмага муниципаль (административ) идарә итүнең аерым функцияләре кергән булса, муниципаль хезмәттән җибәрелгәннән соң ике ел дәвамында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынында үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссиянең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнә торган тәртиптә бирелгән ризалыгыннан башка әлеге оешмада хезмәт шартнамәсе шартларында вазыйфалар биләргә һәм (яисә) федераль законнарда каралган очракларда граждан-хокук шартнамәсе шартларында эш башкарырга хокуксыз.

## 17 статья. **Муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу**

1. Мәнфәгатьләр конфликты дигәндә, муниципаль хезмәткәрнең шәхси кызыксынучанлыгы (турыдан-туры яисә башка рәвешле) аның вазыйфаи бурычларны объектив үтәвенә тәэсир итә торган яисә тәэсир итәргә мөмкин булган һәм шуның нәтиҗәсендә муниципаль хезмәткәрнең шәхси кызыксынучанлыгы белән гражданнарның, оешмаларның, җәмгыятьнең, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекнең законлы мәнфәгатьләре арасында гражданнарның, оешмаларның, җәмгыятьнең, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекнең шушы законлы мәнфәгатьләренә зыян китерергә сәләтле каршылык барлыкка килә торган яисә барлыкка килергә мөмкин булган вәзгыять дип аңларга кирәк.

2. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси кызыксынучанлыгы дигәндә, муниципаль хезмәткәр тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә акчалата йә әйберләтә керемнәр алу (нигезсез баю), муниципаль хезмәткәрнең үзе өчен, аның гаилә әгъзалары яисә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясындагы 1 өлешенең 5 пунктында күрсәтелгән затлар, шулай ук муниципаль хезмәткәр финанс яисә башка йөкләмәләр буенча бәйле булган

гражданнар яисә оешмалар өчен матди файда күрү рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге дип аңларга кирәк.

3. Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә аны җайга салу мәнфәгатьләр конфликтында катнашучы муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи яисә хезмәттәге дәрәҗәсен үзгәртүгә, хәтта билгеләнгән тәртиптә аны вазыйфаи (хезмәт) бурычларын үтәүдән тулысынча читләштерүгә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгуга сәбәп булган файданы алудан баш тартуга китерергә мөмкин.

4. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затның кыйммәтле кәгазьләргә, акцияләргә (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләренә, пайларына) ия булуы мәнфәгатьләр конфликтына китерсә яисә китерергә мөмкин булса, күрсәтелгән зат үзенә караган кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләрен, пайларын) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә ышанычлы идарә итүгә тапшырырга тиеш.

5. Мәнфәгатьләр конфликтында катнашучы муниципаль хезмәткәр тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә аны җайга салу чаралары күрелмәү муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән җибәрүгә китерерлек хокук бозу булып санала.

6. Муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында үзенә мәгълүм булган яллаучы вәкиле (эш бирүче) мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш, хәтта әлеге муниципаль хезмәткәрне конфликтны җайга салу чорына биләнүче муниципаль хезмәт вазыйфасыннан тулысынча читләштерүгә кадәр, мондый очракта биләнүче муниципаль хезмәт вазыйфасыннан тулысынча читләштерелгән барлык вакытка аның акчалата хезмәт хакы сакланып кала.

7. Үзенә буйсынган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында мәгълүм булган яллаучының вәкиле булып торучы муниципаль хезмәткәр тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу чаралары күрелмәү яллаучының вәкиле булып торучы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән җибәрүгә китерерлек хокук бозу булып санала.

8. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынында үз-үзләрен тотуның гомуми принципларын үтәүне тәэмин итү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу өчен җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында әлеге Кодекста һәм муниципаль хокукый актта билгеләнә торган тәртиптә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынында үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр (әлеге статьяда алга таба – Комиссия) төзелергә мөмкин.

9. Комиссия җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең хокукый акты белән даими булмаган нигездә формалаша. Күрсәтелгән актта Комиссиянең санлы һәм персональ составы, аның эшләү вакыты һәм тәртибе билгеләнә.

10. Комиссия составына яллаучы вәкиле (эш бирүче) һәм (яисә) ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук фән һәм мәгариф учреждениеләреннән,

башка оешмалардан бәйсез экспертлар – муниципаль хезмәткә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр (аларның шәхси белешмәләрен күрсәтмичә) буларак чакырылучы вәкилләр керә. Бәйсез экспертларның саны Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.

11. Комиссия составы Комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясый ала торган мәнфәгатьләр конфликтларының барлыкка килү мөмкинлеген калдырмый торган рәвештә булдырыла.

## 18 статья. **Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру**

1. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвачы гражданнар, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш. Күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән тәртиптә, вакытта һәм рәвештә тапшырыла.

2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль вазыйфаны биләүче муниципаль хезмәткәр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшыру тәртибе һәм рәвеше буенча үзенең чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында белешмәләр тапшырырга тиеш.

3. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары керемнәренә туры килүен контрольдә тоту «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында, әлеге Кодекста, Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә башкарыла.

4. Әлеге статья нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора, әгәр алар дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләргә федераль законнар белән кертелмәгән булса.

5. Муниципаль хезмәткәрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрдән муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының түләү сәләтен билгеләү яисә ачыклау өчен, шулай ук турыдан-туры яисә башка рәвештә дини яисә бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең, башка оешмаларның, физик затларның фондларына иганәләр (кертемнәр) җыю өчен файдалану рөхсәт ителми.

6. Муниципаль хезмәткәрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне фаш итүдә яисә әлеге белешмәләрне Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда файдалануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

7. Муниципаль хезмәткәрнең үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булып та, аларны тапшырмау йә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән җибәрүгә китерерлек хокук бозу булып санала.

8. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвачы гражданнар тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткә урнашканда Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә гражданнар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан чикләүләрнең һәм тыюларның, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлүен, аларның «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән бурычларны үтәвен тикшерү Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актларында билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

9. Муниципаль органнар мәнфәгатьләрендә тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвачы гражданнарга, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләргә, мондый гражданнарның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хатыннарына (ирләренә) һәм балигъ булмаган балаларына карата закон белән саклана торган банк, салым серен яисә башка серне тәшкил итә торган белешмәләр тапшыру турындагы соратулар, оператив-эзләнү чараларын башкару турында хокук саклау органнарына соратулар Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан җибәрелә.

10. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның чыгымнарын, шулай ук аларның хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын тикшереп торуны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт органы (коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы дәүләт органы бүлекчәсе йә күрсәтелгән органның вазыйфаи заты) Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

## 4 бүлек. **Муниципаль хезмәткә урнашу, аны үтү һәм туктату тәртибе**

### 19 статья. **Муниципаль хезмәткә урнашу**

1. Муниципаль хезмәткә 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясе дәүләт телен белгән һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон һәм әлеге Кодекс нигезендә билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүче гражданнар «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясында күрсәтелгән муниципаль хезмәткә бәйле чикләүләр сыйфатындагы хәлләр булмаганда урнашырга хокуклы.

2. Муниципаль хезмәткә урнашканда, шулай ук аны үткәндә, җенесенә, расасына, милләтенә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи дәрәҗәсенә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, нинди иҗтимагый берләшмәдән булуына, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең һөнәри һәм эшлекле сыйфатларына бәйле булмаган башка хәлләргә карап, теләсә нинди турыдан-туры яисә бүтән рәвешле чикләүләр яки өстенлекләр билгеләү рөхсәт ителми.

3. Граждан муниципаль хезмәткә урнашканда түбәндәгеләрне тапшыра:

1) муниципаль хезмәткә урнашу һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү турында үтенече булган гаризасын;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән рәвеш буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзасы салынган анкетасын;

3) паспортын;

4) хезмәт кенәгәсен, хезмәт шартнамәсен (контрактын) беренче мәртәбә төзү очракларыннан тыш;

5) белеме турындагы документын;

6) мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгын, хезмәт шартнамәсен (контрактын) беренче мәртәбә төзү очракларыннан тыш;

7) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турындагы таныклыгын;

8) хәрби исәпкә кую документларын – хәрби бурычлылар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

9) муниципаль хезмәткә урнашуга комачауларлык авыруы булмавы турында медицина учреждениесе бәяләмәсен;

10) муниципаль хезмәткә урнашу елы алдындагы бер ел эчендә керемнәре турындагы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләрен;

11) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документларны.

4. Граждан тарафыннан муниципаль хезмәткә урнашканда «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон һәм әлеге Кодекс нигезендә тапшырылган белешмәләр федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин. Аерым муниципаль берәмлекләрдә граждан тарафыннан

муниципаль хезмәткә урнашканда тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүгә карата федераль законнар белән өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.

5. Әлеге статьяның 4 өлешендә каралган тикшерү барышында гражданның муниципаль хезмәткә урнашуына комачауларлык хәлләр билгеләнгән очракта күрсәтелгән гражданга муниципаль хезмәткә урнашуны кире кагу сәбәпләре турында язмача хәбәр ителә.

6. Гражданның муниципаль хезмәткә урнашуы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, хезмәт законнары нигезендә хезмәт шартнамәсе шартларында муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла.

7. Җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча шушы вазыйфага урнашучы граждан контракт төзи. Җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча биләү тәртибе һәм күрсәтелгән вазыйфага контракт буенча билгеләп куела торган зат белән контракт төзү һәм аны өзү тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон белән билгеләнә. Җирле администрация башлыгы вазыйфасына контракт буенча билгеләп куела торган зат белән төзелә торган контрактның үрнәк рәвеше әлеге Кодекска 3 нче кушымта белән билгеләнә.

8. Гражданның муниципаль хезмәткә урнашуы муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую турында эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) акты белән рәсмиләштерелә.

9. Муниципаль хезмәткә урнашканда хезмәт шартнамәсе яклары эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) һәм муниципаль хезмәткәр була.

10. Муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куелганнан соң муниципаль хезмәткәргә хезмәт таныклыгы бирелә. Муниципаль хезмәткәрнең хезмәт таныклыгын бирү тәртибе һәм аның рәвеше муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан раслана.

20 статья. **Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс**

1. Муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгәндә хезмәт шартнамәсе төзегәнче конкурс үткәрелергә мөмкин, конкурс барышында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү башкарыла.

2. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы кабул итә торган муниципаль хокукый акт белән билгеләнә. Конкурс үткәрү тәртибе аның шартларын, аны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турындагы белешмәләрне, шулай ук хезмәт шартнамәсе проектын конкурс үткәреләчәк көнгә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгаруны күз алдында тотарга тиеш. Муниципаль берәмлектә конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны һәм аны төзү тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.

3. Эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) хезмәт шартнамәсе төзи һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе сайлап алган кандидатларның берсен муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куя.

21 статья. **Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү**

1. Муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү муниципаль хезмәтнең үзе били торган вазыйфасына аның туры килү-килмәвен ачыклау максатларында уздырыла. Муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү өч елга бер мәртәбә уздырыла.

2. Түбәндәге муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү үткәрелмәскә тиеш:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасын бер елдан да кимрәк биләүчеләрне;

2) 60 яшькә җиткәннәрне;

3) йөкле хатыннарны;

4) йөклелек һәм бала тудыру буенча отпускта яисә өч яшенә җитмәгән баласын карау буенча отпускта булганнарны. Күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү алар отпусктан чыкканнан соң кимендә бер ел узгач кына мөмкин була;

5) муниципаль хезмәт вазыйфасын вакытлы хезмәт шартнамәсе (контракт) нигезендә биләүчеләрне.

3. Аттестация комиссиясе муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәрнең үзе били торган муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килүе яисә туры килмәве хакында карар чыгара. Аттестация комиссиясе аерым муниципаль хезмәткәрләрне эшләрендә ирешкән уңышлары өчен бүләкләү турында, шул исәптән аларны югарырак вазыйфага билгеләү турында тәкъдимнәр бирергә, ә кирәк чакта аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлеген яхшырту турында тәкъдимнәр бирергә мөмкин. Аттестация нәтиҗәләре аттестацияләнгән муниципаль хезмәткәрләргә тавыш бирү йомгаклары ясалганнан соң ук хәбәр ителә. Аттестацияләү материаллары эшкә яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) тапшырыла.

4. Аттестацияләү нәтиҗәләре буенча эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) аерым муниципаль хезмәткәрләрне эшләрендә ирешкән уңышлары өчен бүләкләү турында яисә аттестацияләү көненнән бер айдан да артык булмаган вакытта муниципаль хезмәткәрне аның ризалыгы белән түбәнрәк вазыйфага билгеләү турында карар кабул итә. Аттестацияләү нәтиҗәләре буенча аттестация комиссиясе аерым муниципаль хезмәткәрләрне квалификацияләрен күтәрергә җибәрү турында тәкъдимнәр бирергә мөмкин.

5. Муниципаль хезмәткәр түбәнрәк вазыйфага билгеләүгә риза булмаган яисә муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына аның ризалыгы белән күчерү мөмкинлеге булмаган очракта, эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче), аның үзе били торган вазыйфага квалификациясе җитәрлек булмау аркасында аттестация нәтиҗәләре белән расланган туры килмәвенә бәйле рәвештә, аттестацияләү көненнән бер айдан да артык булмаган вакытта аны муниципаль хезмәттән җибәрергә мөмкин. Шушы аттестация нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәрне эшеннән азат итү яисә аны түбәнрәк вазыйфага билгеләү күрсәтелгән вакыт узганнан соң рөхсәт ителми.

6. Муниципаль хезмәткәр аттестация нәтиҗәләренә суд тәртибендә шикаять белдерү хокукына ия.

7. Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү уздыру турындагы нигезләмә муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү уздыру турындагы үрнәк нигезләмә нигезендә, әлеге Кодекска 4 нче кушымтага таянып, муниципаль хокукый акт белән раслана.

22 статья. **Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясе**

1. Муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге җирле үзидарә органы җитәкчесе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе яисә муниципаль хокукый акт белән вәкаләт тапшырылган бүтән вазыйфаи зат тарафыннан раслана торган вазыйфаи инструкция нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясенә түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәргә карата белемнәренең һәм күнекмәләренең дәрәҗәсенә һәм характерына, шулай ук белеменә, муниципаль хезмәт (дәүләт хезмәте) стажына яисә белгечлек буенча эш стажына квалификация таләпләре;

2) муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычлары, хокуклары һәм җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты эшчәнлеген җайга сала торган акт, җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты бурычлары һәм функцияләре, муниципаль хезмәтнең шунда биләнә торган вазыйфасының функциональ үзенчәлекләре нигезендә вазыйфаи бурычларын үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыгы;

3) муниципаль хезмәткәр мөстәкыйль рәвештә идарәчел һәм бүтән төрле карарлар кабул итәргә хокуклы яисә бурычлы булган мәсьәләләр исемлеге;

4) муниципаль хезмәткәр норматив хокукый актлар проектларын һәм (яисә) идарәчел һәм бүтән төрле карарлар проектларын әзерләгәндә катнашырга хокуклы яисә бурычлы булган мәсьәләләр исемлеге;

5) муниципаль хезмәтнең биләнә торган вазыйфасы буенча карарлар проектлары әзерләү, карау вакытлары һәм процедуралары, аларны килештерү һәм кабул итү тәртибе;

6) муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын башкаруына бәйле рәвештә җирле үзидарәнең шул ук органындагы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратындагы муниципаль хезмәткәрләр белән, җирле үзидарәнең башка органнары муниципаль хезмәткәрләре, гражданнар һәм оешмалар белән хезмәттәге үзара мөнәсәбәтләре процедуралары.

3. Вазыйфаи инструкция нигезләмәләре муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү уздырганда, аның һөнәри хезмәт эшчәнлеген планлаштырганда исәпкә алына.

4. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкцияне үтәү нәтиҗәләре муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздырганда яисә муниципаль хезмәткәрне кадрлар резервына керткәндә, муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү

уздырган йә бүләкләгән вакытта аның һөнәри хезмәт эшчәнлеген бәяләгәндә исәпкә алына.

### 23 статья. **Муниципаль хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсен өзү өчен нигезләр**

1. Хезмәт шартнамәсен өзү өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексында каралган нигезләрдән тыш, муниципаль хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсе түбәндәге очракларда шулай ук эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) тәкъдиме белән дә өзелергә мөмкин:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән иң чик яшькә җитү;

2) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнаша торган чит дәүләт гражданлыгын туктату, муниципаль хезмәткәрнең чит дәүләт гражданлыгын алуы яки чит дәүләт гражданлыгына ия Россия Федерациясе гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашмый торган чит дәүләт территориясендә Россия Федерациясе гражданының яшәүгә рөхсәт яисә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алуы;

3) муниципаль хезмәткә бәйле һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13, 14, 14[1] һәм 15 статьяларында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәү;

4) дисквалификацияләү рәвешендә административ җәза кулланылу.

2. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен билгеләнгән иң чик яшькә җиткән муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәттә булу вакыты озайтылырга мөмкин. Муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттә булу вакытын бер мәртәбә озайту бер елдан да артыгракка рөхсәт ителми.

## 5 бүлек. **Эш (хезмәт) вакыты һәм ял вакыты**

### 24 статья. **Эш (хезмәт) вакыты**

Муниципаль хезмәткәрләрнең эш (хезмәт) вакыты хезмәткә кагылышлы законнар нигезендә җайга салына.

### 25 статья. **Муниципаль хезмәткәрнең отпускы**

1. Муниципаль хезмәткәргә, муниципаль хезмәтнең үзе били торган вазыйфасы һәм уртача хезмәт хакын исәпләп чыгару өчен хезмәт законнарында урнаштырылган тәртиптә күләме билгеләнә торган акчалата вазыйфаи тулы кереме сакланган килеш, еллык отпуск бирелә.

2. Муниципаль хезмәткәрнең еллык түләүле отпускын түләүле төп отпуск һәм түләүле өстәмә отпусклар тәшкил итә.

3. Муниципаль хезмәтнең югары һәм баш вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә еллык түләүле төп отпуск 35 календарь көн дәвамлылыгында бирелә. Муниципаль хезмәтнең башка төркемнәре вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә еллык түләүле төп отпуск 30 календарь көн дәвамлылыгында бирелә.

4. Муниципаль хезмәткәргә еллык түләүле өстәмә отпусклар тиешле еллар эшләгән өчен, шулай ук федераль законнарда һәм әлеге Кодекста каралган очракларда бирелә. Муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен еллык түләүле өстәмә отпускның дәвамлылыгы муниципаль хезмәтнең һәр елы өчен бер календарь көн исәбеннән чыгып санала. Еллык түләүле төп отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен еллык түләүле өстәмә отпускның гомуми дәвамлылыгы 45 календарь көннән артмаска тиеш. Нормалаштырылмаган эш көне өчен еллык түләүле өстәмә отпуск, шулай ук федераль законнарда каралган башка очракларда бирелә торган еллык түләүле өстәмә отпусклар еллык түләүле төп отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен еллык түләүле өстәмә отпускның әлеге өлештә каралган гомуми дәвамлылыгына өстәп бирелә.

5. Муниципаль хезмәткәрнең гаризасы буенча еллык түләүле отпуск өлешләп тә бирелергә мөмкин, бу чакта отпускның бер өлеше дәвамлылыгы 14 календарь көннән ким булмаска тиеш. Эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) белән килешеп, муниципаль хезмәткәргә отпуск өлеше бүтән дәвамлылыкта да бирелергә мөмкин.

6. Муниципаль хезмәткәргә аның язма гаризасы буенча эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) карары белән, акчалата вазыйфаи тулы керем сакланмыйча, күп дигәндә бер ел дәвамлылыгында отпуск бирелергә мөмкин.

7. Муниципаль хезмәткәргә федераль законнарда каралган очракларда акчалата вазыйфаи тулы керем сакланмыйча гына отпуск бирелә.

## 6 бүлек. **Муниципаль хезмәткәргә хезмәте өчен түләү, муниципаль хезмәткәргә бирелә торган гарантияләр, муниципаль хезмәт стажы**

### 26 статья. **Муниципаль хезмәткәргә хезмәте өчен түләү**

1. Муниципаль хезмәткәргә хезмәте өчен түләү муниципаль хезмәткәрнең үзе биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы нигезендә вазыйфаи оклады (алга таба – вазыйфаи оклад), шулай ук әлеге Кодекс белән билгеләнә торган айлык һәм башка өстәмә түләүләр (алга таба – өстәмә түләүләр) тәшкил итә торган акчалата вазыйфаи тулы керем рәвешендә гамәлгә ашырыла.

2. Өстәмә түләүләргә түбәндәгеләр керә:

1) вазыйфаи окладка тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә;

2) вазыйфаи окладка муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен айлык өстәмә;

3) аеруча мөһим һәм катлаулы йөкләмәләрне үтәгән өчен премияләр, аларны түләү тәртибе, муниципаль орган бурычларын һәм функцияләрен тәэмин итүне, вазыйфаи инструкция үтәлешен исәпкә алып, эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) тарафыннан билгеләнә;

4) айлык акчалата кызыксындыру;

5) класс чины өчен айлык өстәмә;

6) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү;

7) матди ярдәм.

3. Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләрне истә тотып, муниципаль хокукый актлар белән түбәндәге өстәмә түләүләр каралырга мөмкин:

1) нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык компенсация түләве;

2) хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, аларны юрист яисә башкаручы сыйфатында имзалау төп хезмәт вазыйфаларына керә торган, югары юридик белемгә ия муниципаль хезмәткәрләргә айлык түләү (юридик эш өчен өстәмә);

3) профильле фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе, фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе булган муниципаль хезмәткәрләргә вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

4) Татарстан Республикасы мактаулы исеме өчен муниципаль хезмәткәрләргә вазыйфаи окладка айлык өстәмә.

4. Муниципаль хезмәткәргә дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр белән эшләгәне өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, күләмдә һәм тәртиптә вазыйфаи окладка айлык өстәмә билгеләнә.

5. Җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәргә хезмәт өчен түләү күләмен һәм шартларын мөстәкыйль рәвештә билгели. Вазыйфаи оклад күләме, шулай ук айлык һәм бүтән өстәмә түләүләр күләме, аларны түләү тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә чыгарыла торган муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

27 статья. **Муниципаль хезмәткәргә бирелә торган гарантияләр**

1. Муниципаль хезмәткәргә түбәндәгеләр гарантияләнә:

1) вазыйфаи инструкция нигезендә аның вазыйфаи бурычларын үтәвен тәэмин итәрлек эш шартлары;

2) акчалата вазыйфаи тулы керемне вакытында һәм тулы күләмдә алу хокукы;

3) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү, ял көннәре һәм эш көннәре булмаган бәйрәм көннәре, шулай ук еллык түләүле отпуск бирү юлы белән тәэмин ителә торган ял;

4) муниципаль хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына, шул исәптән муниципаль хезмәткәр пенсиягә чыкканнан соң да, медицина хезмәте күрсәтү;

5) тиешле еллар эшләгән өчен һәм инвалидлыкка бәйле рәвештә пенсия тәэминаты, шулай ук, муниципаль хезмәткәр вазыйфаи бурычларын үтәгәндә вафат булган очракта, муниципаль хезмәткәрнең гаилә әгъзаларына пенсия тәэминаты;

6) вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян килү очрагына мәҗбүри дәүләт иминләштерүе;

7) муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт узган чорда яисә муниципаль хезмәттән киткәннән соң, әмма вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә авырган яисә хезмәткә сәләтен югалткан очракка мәҗбүри дәүләт социаль иминләштерүе;

8) муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә көч кулланулардан, янаулардан һәм хокукка каршы башка гамәлләрдән федераль законнарда билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда яклау.

2. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бетүгә йә җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты хезмәткәрләре штатын кыскартуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсен өзгәндә, муниципаль хезмәткәргә оешма ябылуга йә оешманың хезмәткәрләр штаты кыскартуга бәйле рәвештә эштән җибәрү очрагында хезмәткәрләр өчен хезмәт законнарында билгеләнгән гарантияләр бирелә.

3. Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль берәмлек уставы белән муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә гарантияләр бирелергә мөмкин.

### 28 статья. **Муниципаль хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына пенсия тәэминаты**

1. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарында, муниципаль органнарда (алга таба – җирле үзидарә органнары) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән муниципаль хезмәткәрләр, түбәндәге шартлар булганда, тиешле еллар эшләгән өчен әлеге Кодекс нигезендә пенсия (алга таба – тиешле еллар эшләгән өчен пенсия) алу хокукына ия:

1) кимендә 15 ел муниципаль хезмәт стажы;

2) муниципаль хезмәттән җибәрелүе түбәндәге сәбәпләрнең берсе аркасында булса:

а) җирле үзидарә органын бетерү яисә җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрләр штатын кыскарту (муниципаль хезмәт вазыйфасын кыскарту);

б) муниципаль вазыйфаны биләүче зат үз вәкаләтләрен үтәүне туктатуга бәйле рәвештә, әлеге зат вәкаләтләрен үтәүне турыдан-туры тәэмин итү өчен гамәлгә куелган вазыйфадан җибәрү;

в) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән иң чик яшькә җитү;

г) муниципаль хезмәтне дәвам итүгә комачаулардык сәламәтлеге торышы аркасында, билгеләнгән тәртиптә бирелгән медицина бәяләмәсе нигезендә муниципаль хезмәтнең биләнә торган вазыйфасына туры килмәве ачыклану;

д) картлык (инвалидлык) буенча хезмәт пенсиясенә чыгу;

е) дәүләт вазыйфасына сайлану яисә билгеләп куелу, муниципаль вазыйфага сайлану яисә билгеләп куелу, һөнәр берлеге органында, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органында, түләүле сайланулы вазыйфага сайлану (делегат итеп җибәрелү);

ж) үз теләге буенча йә хезмәт шартнамәсе яклары килешүе буенча эштән җибәрү;

з) җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча биләүче зат вәкаләтләренең билгеләнгән чоры тәмамлану;

3) «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон) нигезендә картлык (инвалидлык) буенча пенсия билгеләнү.

2. Муниципаль хезмәткәр картлык буенча хезмәт пенсиясен алу хокукы бирерлек яшькә җиткәнче әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктының «ж» пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча эштән җибәрелгән очракта, күрсәтелгән яшькә җиткәч муниципаль хезмәткәрнең тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу яисә аңа инвалидлык буенча пенсия билгеләү хокукы сакланып кала, бу чакта аның муниципаль хезмәттән азат ителгән көнгә кимендә 15 ел муниципаль хезмәт стажы булу шарт.

3. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә билгеләнгән картлык (инвалидлык) буенча хезмәт пенсиясенә карата исәпләнә һәм аның белән бергә түләнә. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия гомер буена билгеләнә.

4. Муниципаль хезмәт стажы 15 ел булганда, муниципаль хезмәткәрләргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата вазыйфаи тулы керемнең 20 проценты күләмендә билгеләнә. Муниципаль хезмәт стажының 15 елдан артып киткән һәр тулы елы өчен тиешле еллар эшләгән өчен пенсия айлык акчалата вазыйфаи тулы керемнең 3 процентына арттырыла. Шул ук вакытта тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләме муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата вазыйфаи тулы керемнең 50 процентыннан артыграк була алмый. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиянең әлеге өлеш нигезендә билгеләнгән күләме картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты нигезендә билгеләнеп беркетелгән база күләменнән кимрәк булса, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминият өлешенең беркетелгән база күләменә тигез күләмдә түләнә.

5. Муниципаль хезмәткәрнең тиешле еллар эшләгән өчен пенсиясе күләмен билгеләү әлеге Кодекста билгеләнгән нигездә муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәтендә башкарыла. Муниципаль хезмәткәрнең тиешле еллар эшләгән өчен пенсиясенең максималь күләме Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең шундый ук вазыйфасында тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсиясенең максималь күләменнән артыграк булмаска тиеш.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы буенча тиешле еллар эшләгән өчен пенсиянең максималь күләмен исәпләп чыгарганда, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи окладның максималь күләме кулланыла (әгәр вазыйфаи оклад максималь һәм минималь күләмдә булса), ә стаж озынлыгы һәм айлык түләүләр тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәр өчен әлеге Кодекс нигезендә билгеләнгән шундый ук күләмнәрдә исәпкә алына.

7. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен исәпләү тиешле еллар эшләгән өчен пенсия бирүне сорап мөрәҗәгать иткән затның теләге буенча, муниципаль хезмәтне туктаткан көнгә яисә картлык буенча хезмәт пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткән көнгә муниципаль хезмәтнең ул биләгән вазыйфасы буенча йә муниципаль хезмәттәге башка вазыйфада эшләү вакыты кимендә тулы 12 ай булу шарты белән, шушы вазыйфасы буенча айлык акчалата вазыйфаи тулы керемнән чыгып башкарыла. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән мизгелгә муниципаль хезмәтнең күрсәтелгән вазыйфалары бетерелгән очракта, акчалата вазыйфаи тулы керем күләме муниципаль хезмәтнең шундый ук вазыйфасы йә шуңа тиңләштерелгән вазыйфасы буенча билгеләнә. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының тәңгәллеге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү өчен урнаштырылган тәртиптә билгеләнә.

8. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия исәпләп чыгарганда һәм билгеләгәндә алына торган айлык акчалата вазыйфаи тулы керем составына вазыйфаи оклад һәм вазыйфаи окладка тиешле еллар эшләгән өчен, муниципаль хезмәттәге аерым шартлар өчен, класс чины өчен, профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык өстәмәләр керә. Бу чакта вазыйфаи окладка муниципаль хезмәттәге аерым шартлар өчен айлык өстәмә муниципаль хезмәткәр эштән җибәрелгән көнгә кадәр кимендә алты ай алданрак билгеләнгән күләмдә кертелә. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен исәпләп чыгарганда әлеге өлеш нигезендә исәпкә алына торган айлык түләүләр айлык акчалата вазыйфаи тулы керем составына бары тик алар муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасында фактта алынган булса гына кертеләләр.

9. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләре нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукына ия булган гражданның гаризасы буенча башкарыла.

10. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү турындагы гаризага түбәндәгеләр өстәлеп бирелә:

1) паспортының яисә шәхесен, яшен, яшәү урынын, гражданлыгын таныклаучы башка документының күчермәсе;

2) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, шулай ук кирәк чакта муниципаль хезмәт стажын раслый торган һәм әлеге Кодексның 30 статьясында күрсәтелгән бүтән документларның күчермәләре;

3) тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән затның муниципаль хезмәткәрнең тиешле вазыйфасы буенча айлык акчалата вазыйфаи тулы кереме күләме турында белешмә, анда вазыйфаи окладның һәм айлык түләүләрнең күләме, шулай ук муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә билгеләү датасы булырга тиеш.

11. Әлеге статьяның 10 өлешендәге 1 – 3 пунктларында күрсәтелгән документларның күчермәләре белән бергә аларның төп нөсхәләре дә тапшырыла, төп нөсхәләре документларны кабул итеп алганда күчермәләре белән чагыштырыла һәм гариза бирүчегә кире кайтарыла.

12. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия түләү тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләнгән затның яшәү урыны буенча башкарыла. Пенсионер яшәү

урынын алмаштырган очракта, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия түләү, аны китереп бирүне дә оештырып, анның яңа яшәү урыны яисә тору урыны буенча пенсия эше һәм теркәү исәбе органнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелгән теркәү турындагы документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

13. Татарстан Республикасы территориясеннән читкә даими яшәү өчен китүче (киткән) затларга тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләр түләү Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләр түләү өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

14. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия гариза биргән көннән билгеләнә һәм түләнә, әмма бу гамәл муниципаль хезмәт вазыйфасыннан яисә муниципаль вазыйфадан, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан яисә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасыннан, йә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазыйфасыннан яисә дәүләт граждан хезмәте вазыйфасыннан, йә Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасыннан яисә федераль дәүләт хезмәте вазыйфасыннан азат ителгән һәм «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык (инвалидлык) буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгән көннең иртәгесеннән дә алданрак башкарыла алмый.

15. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләнгән зат әлеге статьяның 14 өлешендә күрсәтелгән вазыйфаны биләгән очракта, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия түләү шул вазыйфаларның берәрсен били башлаган көннән туктатып торыла. Шушы затлар күрсәтелгән вазыйфалардан азат ителгәннән соң, аларга тиешле еллар эшләгән өчен пенсия түләү элеккеге шартларда яңартыла йә аларның гаризалары буенча Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарындагы муниципаль хезмәтнең соңгы вазыйфасы буенча әлеге Кодекс нигезендә яңадан пенсия билгеләнә.

16. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсияне индексацияләү (өстәмә арттыру), муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары үзәкләштерелгән тәртиптә арттырылганда, әлеге статьяның 4 өлеше кагыйдәләре буенча саналган тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи окладларны арттыру индексына арттыру юлы белән башкарыла.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен яңадан исәпләү (корректировкалау) пенсионер гаризасы буенча муниципаль хезмәт стажы дәвамлылыгын билгеләнгән тәртиптә әлеге статьяның 4 һәм 7 өлешләре нигезендә үзгәрткәндә башкарыла. Бу очракта пенсия күләмен яңадан исәпләү пенсионер гаризасын кабул итеп алган айдан соң килүче айның беренче числосыннан гамәлгә ашырыла. Гариза мондый яңадан исәпләүне башкару өчен кирәкле барлык документлар бер үк вакытта тапшырылганда гына кабул итеп алына.

17. Федераль законнарда яисә Татарстан Республикасы законнарында башкасы билгеләнмәгән булса, бер үк вакытта тиешле еллар эшләгән өчен әлеге Кодекс нигезендә пенсия белән тәэмин ителү һәм дәүләт граждан хезмәткәренең тиешле еллар эшләгән өчен пенсиясен алу, гомере буена айлык вазыйфаи тулы керем алу, гомере буена өстәмә рәвештә айлык матди тәэмин ителү, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә дәүләт пенсиясенә бүтән өстәмә алу хокукына ия булган муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар

эшләгән өчен әлеге Кодекс нигезендә пенсия түләнә яисә аның теләге буенча башка түләү башкарыла.

18. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләр билгеләүне, аларның күләмнәрен яңадан исәпләп чыгаруны һәм түләүне, аларны китереп бирүне оештыруны да кертеп, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләр билгеләүне һәм түләүне башкара торган орган гамәлгә ашыра.

19. Әгәр әлеге Кодекста башкасы каралмаган булса, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия түләү, аны китереп бирү, пенсиядән тотып калулар хезмәт пенсиясен түләү, китереп бирү һәм аннан тотып калулар өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

20. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүне сорап мөрәҗәгать итү, пенсия билгеләү һәм аның күләмен яңадан исәпләп чыгару, пенсия түләү, пенсия документациясен алып бару, әлеге Кодекста каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләр билгеләү һәм түләү өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

21. Муниципаль хезмәткәр вазыйфаи бурычларын башкаруга бәйле рәвештә, шул исәптән муниципаль хезмәттән җибәрелүеннән соң вафат булган очракта, мәрхүмнең гаилә әгъзалары караучысын югалту очрагына федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә пенсия алырга хокуклы.

29 статья. **Муниципаль хезмәт стажы**

1. Муниципаль хезмәт стажына (гомуми дәвамлылыгына) түбәндәге урыннарда даими (штатта) эшләгән чорлар керә:

1) муниципаль хезмәт вазыйфаларында (муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфаларында). Мондый очракта 2006 елның 1 гыйнварыннан муниципаль хезмәт стажына Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарында Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрында, ә ул расланганчы – Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфалары реестрында каралган вазыйфаларда;

2) муниципаль вазыйфаларда;

3) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларында һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында, әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы (Татарстан АССР) дәүләт органнарында башка дәүләт вазыйфаларында;

4) Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларында, федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларында һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында, СССР, союздаш һәм автономияле республикалар, крайлар, өлкәләр, автономияле өлкәләр һәм автономияле округлар дәүләт органнарындагы, даими нигездә халык депутатларының районнар, шәһәрләр, шәһәрләрдәге районнар, поселок һәм авыл Советларындагы һәм аларның башкарма комитетларындагы, шул исәптән сайланулы вазыйфаларда, әгәр күрсәтелгән вазыйфаларда эшләү (хезмәт узу) вакыты федераль законнар нигезендә федераль дәүләт граждан хезмәтенең тиешле

еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукын бирә торган стажын хисаплаганда исәпкә алынса;

5) хезмәт (хәрби хезмәт) узу хәрби хезмәттә булган, эчке эшләр органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, җинаять-үтәтү системасы органнарында хезмәт узган затларга Россия Федерациясе законнары нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү максатында тиешле елларга кертелә торган вазыйфаларда (хәрби вазыйфаларда);

6) федераль салым полициясе органнары, наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең әйләнешен тикшереп тору органнары хезмәткәрләренең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә раслана торган вазыйфалар исемлеге нигезендә билгеләнә торган вазыйфаларында;

7) Россия Федерациясе таможня органнары хезмәткәрләренең федераль закон нигезендә билгеләнә торган вазыйфаларында;

8) прокурор хезмәткәрләренең федераль закон нигезендә билгеләнә торган вазыйфаларында;

9) һөнәр берлекләре органнарына сайлану (делегат итеп җибәрелү) сәбәпле федераль закон нигезендә дәүләт органнарындагы яисә җирле үзидарә органнарындагы вазыйфалардан азат ителгән хезмәткәрләр һөнәр берлекләре органнарында били торган вазыйфаларда, моңа, элекке вазыйфасыннан азат ителеп, дәүләт органында яисә җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасы органына сайланган (делегат итеп җибәрелгән) һөнәр берлеге хезмәткәрләре били торган вазыйфалар да керә;

10) түбәндәгеләрдәге җитәкчеләр, белгечләр, хезмәткәрләр вазыйфаларында, сайланулы вазыйфаларда:

а) 1991 елның 6 ноябренә кадәр, шул көнне дә кертеп, КПССның үзәк, республика, өлкә һәм район (шәһәр) органнарында, шулай ук райкомнар хокуклары булган предприятиеләрдәге, оешмалардагы парткомнарда;

б) 1990 елның 26 октябренә кадәр, шул көнне дә кертеп, республика һәм җирле һөнәр берлекләре органнары аппаратларында;

11) 2001 елның 1 гыйнварыннан алып 2013 елның 31 мартына кадәр, шул көнне дә кертеп, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлекчәсенең, Россия Федерациясе Пенсия фондының районнардагы һәм шәһәрләрдәге идарәләренең җитәкчеләре, белгечләре вазыйфаларында.

2. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы (Татарстан АССР) дәүләт органнарында башка дәүләт вазыйфаларын биләү чорлары муниципаль хезмәт стажына түбәндәге тәртиптә кертелә:

1) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларының җыелма исемлегендә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрында каралган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларында һәм дәүләт хезмәте вазыйфаларында, шулай ук дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрына кертелмәгән вазыйфаларда, соңыннан бу вазыйфаларны дәүләт хезмәте вазыйфаларының тиешле исемлегенә керткән очракларда, шушы Реестр расланганнан соң эшләү (хезмәт узу) чорлары;

2) 1995 елның 26 маеннан башлап Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларының җыелма исемлеге һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры расланганчы, Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең дәүләт вазыйфалары реестрында каралган вазыйфаларда, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең дәүләт вазыйфалары реестрында каралмаган вазыйфаларда, соңыннан бу вазыйфаларны дәүләт вазыйфаларының яисә дәүләт хезмәте вазыйфаларының тиешле исемлегенә керткән очракларда, эшләү (хезмәт узу) чорлары;

3) 1995 елның 26 маена кадәр җитәкчеләр, белгечләр, хезмәткәрләр вазыйфаларын, сайланулы вазыйфаларны түбәндәгеләрдә биләү чорлары:

а) Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында;

б) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында һәм аның Аппаратында, Татарстан Республикасы Дәүләт (парламент) контроле комитетында һәм аның аппаратында;

в) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында һәм аның Аппаратында;

г) Татарстан Республикасы Президенты билгели торган исемлек буенча Татарстан Республикасы министрлыкларында, дәүләт комитетларында, дәүләт идарәсенең башка органнарында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы дәүләт идарәсе органнарында (идарә органнарында);

д) Татарстан Республикасы вәкиллекләрендә;

е) дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең җирле органнарында (халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрләрдәге район Советларында, районнарның, республика әһәмиятендәге шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның администрацияләрендә) һәм аларның аппаратларында;

ж) Татарстан Республикасы Конституция күзәтчелеге комитетында;

з) Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясендә;

4) җитәкчеләрнең, белгечләрнең, хезмәткәрләрнең вазыйфаларын, сайланулы вазыйфаларны түбәндәгеләрдә биләү чорлары:

а) Татарстан Республикасы Югары Советында (Татарстан АССР Югары Советында) һәм Татарстан АССР Югары Советы Президиумында, халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрләрдәге район, поселок, авыл Советларында һәм аларның аппаратларында;

б) Татарстан АССР Министрлар Советында (Татарстан АССР Министрлар Кабинетында) һәм аның аппаратында, халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрләрдәге район, поселок, авыл Советларының башкарма комитетларында;

в) Татарстан Республикасы Президенты билгели торган исемлек буенча Татарстан АССР Министрлар Советының дәүләт идарәсе органнарында, Татарстан АССР Министрлар Советы каршындагы дәүләт идарәсе органнарында, Татарстан АССР министрлыкларында һәм ведомстволарында.

3. Муниципаль хезмәт стажына муниципаль хезмәткәрнең әлеге Кодекс нигезендә яңа һөнәргә өйрәнү, квалификация күтәрү яисә стажировка узу вакыты, шулай ук федераль законнар нигезендә муниципаль хезмәткәр өчен муниципаль хезмәт вазыйфасы сакланып калган башка чорлар кертелә.

4. Муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт стажы дәүләт граждан хезмәткәренең дәүләт граждан хезмәте стажына тиңләштерелә. Муниципаль хезмәт вазыйфаларында эшләү вакыты вазыйфаи окладка тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә билгеләү өчен, тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпуск дәвамлылыгын һәм дәүләт граждан хезмәтендә намуслы һәм нәтиҗәле эшләгән өчен кызыксындыру күләмен билгеләү өчен исәпләнә торган дәүләт граждан хезмәте стажына кертелә.

30 статья. **Муниципаль хезмәт стажын исәпләп чыгару һәм билгеләү тәртибе**

1. Муниципаль хезмәт стажын исәпләп чыгару календарь тәртибендә башкарыла. Муниципаль хезмәт стажын исәпләү хезмәт (эш) чорлары бергә кушыла.

2. Билгеләнгән үрнәктәге хезмәт кенәгәсе муниципаль хезмәт стажын раслый торган төп документ була.

3. Муниципаль хезмәт стажын исәпләгәндә хезмәт кенәгәсендә исәпкә алына торган язулар аларны хезмәт кенәгәсенә керткән көнгә гамәлдә булган хезмәт турындагы законнар нигезендә рәсмиләштерелгән булырга тиеш. Хезмәт кенәгәсендә муниципаль хезмәт стажына кертелә торган хезмәт (эш) чорларын раслау өчен нигез итеп алына торган хаталы яисә төгәл булмаган белешмәләр булган очракларда, хезмәт кенәгәсенә федераль законнарда каралган тәртиптә үзгәрешләр кертелә.

Хезмәт кенәгәсендә муниципаль хезмәт стажын раслый торган язулар булмаган очракларда, әлеге стаж шул стажга кертелә торган вазыйфаларда хезмәт (эш) чорларын раслый торган, вазыйфага билгеләп кую һәм аннан азат итү турындагы документларның күчермәләре белән бергә бирелгән белешмәләр нигезендә раслана.

4. Хәрби хезмәт узу, аңа тиңләштерелгән башка хезмәт узу чорлары, шулай ук федераль салым полициясе органнары, таможня органнары хезмәткәрләренең хезмәт узу чорлары хәрби билетлар, хәрби комиссариатларның, хәрби бүлекчәләрнең, архив учреждениеләренең белешмәләре, хезмәт кенәгәсендәге язулар, хезмәт узу исемлегендәге язулар белән расланырга мөмкин.

5. Әлеге Кодексның 29 статьясында каралган вазыйфалардагы хезмәт (эш) чорларын раслау өчен кирәк булган очракларда хокукый актларның күчермәләре йә вазыйфага билгеләп кую яисә вазыйфадан азат итү турында алардан өземтәләр бирелергә мөмкин.

6. Тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә билгеләү, тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгын, хезмәттә югары уңышларга ирешкән өчен кызыксындырулар күләмен билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын били торган җирле үзидарә органының муниципаль хезмәт стажын билгеләү комиссиясе карары белән билгеләнә. Күрсәтелгән комиссия җирле үзидарә органының хокукый акты белән төзелә.

Муниципаль хезмәт стажын билгеләү комиссиясе турындагы нигезләмәне җирле үзидарә органы раслый.

7. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү максатында муниципаль хезмәт стажы билгеләнгән тәртиптә тапшырылган, муниципаль хезмәт стажын раслый торган документлар нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләрне билгеләү буенча вәкаләтле орган тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүне сораган гаризасы буенча әлеге Кодекс нигезендә билгеләнә.

## 7 бүлек. **Муниципаль хезмәткәрне кызыксындыру, муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы**

### 31 статья. **Муниципаль хезмәткәрне кызыксындыру**

1. Муниципаль хезмәткәр үзенең вазыйфаи бурычларын намуслы һәм нәтиҗәле үтәгән, мактауга лаек булып хезмәт узган, аеруча мөһим һәм катлаулы йөкләмәләрне үтәгән өчен, аңа карата түбәндәге кызыксындыру төрләре кулланылырга мөмкин:

1) рәхмәт белдерү;

2) бер мәртәбә бирелә торган акчалата кызыксындыру түләү;

3) кыйммәтле бүләк белән бүләкләү;

4) мактаулы грамота белән яисә җирле үзидарә органнары билгеләгән бүләкләрнең башка төрләре белән бүләкләү;

5) законнар нигезендә дәүләт бүләкләре белән бүләкләү;

6) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль берәмлек уставында һәм башка муниципаль хокукый актларда билгеләнгән бүтән кызыксындыру төрләре.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган кызыксындыруларны куллану тәртибе һәм шартлары муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

### 32 статья. **Муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы**

1. Муниципаль хезмәткәр дисциплинар гамәл кылган – үзенә йөкләнгән хезмәт бурычларын үз гаебе белән үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) түбәндәге дисциплинар җәза чараларын кулланырга хокуклы:

1) кисәтү;

2) шелтә ясау;

3) тиешле нигезләр буенча муниципаль хезмәттән азат итү.

2. Дисциплинар гамәл кылган муниципаль хезмәткәр вазыйфаи бурычларны үтәүдән, аның дисциплинар җаваплылыгы турындагы мәсьәлә хәл ителгәнче, вакытлыча (әмма бер айдан да озагракка түгел) акчалата хезмәт хакы сакланып, читләштерелергә мөмкин. Бу очракта муниципаль хезмәткәрне вазыйфаи бурычларны үтәүдән читләштерү муниципаль хокукый акт нигезендә башкарыла.

3. Дисциплинар җәзаларны куллану һәм кире алу тәртибе хезмәт турындагы законнарда билгеләнә.

33 статья. **Чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җәзалар**

1. Муниципаль хезмәткәр чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда, «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы көрәш максатларында куелган бурычларны үтәмәгән өчен әлеге Кодексның 32 статьясында каралган җәзалар билгеләнә.

2. Муниципаль хезмәткәр, әлеге Кодексның 17 һәм 18 статьяларында каралган хокук бозуларны кылган очракларда ышаныч югалтуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәттән азат ителергә тиеш.

3. Әлеге Кодексның 17, 18 һәм 32 статьяларында каралган җавапка тартулар эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә кулланыла:

1) тиешле муниципаль органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе (алга таба – хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе) уздырган тикшерү нәтиҗәләре турындагы доклад;

2) әгәр тикшерү нәтиҗәләре турындагы доклад муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә җибәрелсә, комиссия күрсәтмәсе;

3) муниципаль хезмәткәрнең аңлатмалары;

4) башка материаллар.

4. Хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тикшерү уздыру өчен түбәндәгеләр тарафыннан язма рәвештә бирелгән җитәрлек мәгълүмат нигез була:

1) хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары;

2) сәяси партияләрнең региональ яисә җирле бүлекчәләре, шулай ук закон нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булмаган региональ иҗтимагый берләшмәләр;

3) тиешле муниципаль берәмлектә төзелгән иҗтимагый совет;

4) массакүләм мәгълүмат чаралары.

5. Аноним хәбәрләр хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан тикшерү уздыру өчен нигез була алмый.

6. Хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе, тикшерү уздырганчы, муниципаль хезмәткәрдән язма рәвештә аңлатма алырга тиеш. Әгәр муниципаль хезмәткәр әлеге аңлатманы ике эш көне эчендә бирмәсә, тиешле акт төзелә. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан аңлатма бирелмәү тикшерү уздыруга тоткарлык була алмый.

7. Муниципаль хезмәткәр әлеге Кодексның 17 статьясындагы 5 яисә 7 өлешендә каралган хокук бозуларны кылган очракта, тикшерү нәтиҗәләре турында доклад, муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмасы һәм башка материаллар хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә тапшырыла, ул исә эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) өчен муниципаль хезмәткәргә дисциплинар җәза куллану буенча тәкъдимнәр әзерли.

Муниципаль хезмәткәр башка төрле хокук бозган очракта, тикшерү нәтиҗәләре турында доклад, муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмасы һәм башка материаллар хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан эшкә яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) тапшырыла.

8. Әлеге Кодексның 17, 18 һәм 32 статьяларында каралган җавапка тартуларны кулланганда, муниципаль хезмәткәр кылган коррупциячел хокук бозуның характеры, аның авырлыгы, аны кылгандагы шартлар, муниципаль хезмәткәрнең башка чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәве һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәве, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең моңа кадәр үз вазыйфаи бурычларын башкару нәтиҗәләре исәпкә алына.

9. Әлеге Кодексның 17, 18 һәм 32 статьяларында каралган җавапка тартулар муниципаль хезмәткәрнең коррупциячел хокук бозуы ачыкланган көннән бер айдан да соңга калмыйча кулланыла, бу вакытка муниципаль хезмәткәр вакытлыча эшкә сәләтсез булган чор, аның отпускта булуы, мөһим сәбәпләр аркасында хезмәттә булмаган башка очраклар, шулай ук хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан тикшерү уздыру һәм шул тикшерү материалларын муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе тарафыннан карау вакыты керми. Бу вакытта җавапка тарту коррупциячел хокук бозу башкарылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча кулланылырга тиеш.

10. Муниципаль хезмәткәр коррупциячел хокук бозган очракта, аны җавапка тарту турындагы актта җавапка тарту өчен нигез буларак «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның $27^{1}$ статьясындагы 1 яисә 2 өлеш күрсәтелә.

11. Хокук бозуны һәм нигезләмәләре бозылган норматив хокукый актлар күрсәтелгән муниципаль хезмәткәргә карата җавапка тарту куллану турындагы яисә муниципаль хезмәткәргә карата мондый җавапка тарту кулланудан нигезләре күрсәтелгән баш тарту турындагы актның күчермәсе тиешле акт чыгарылган көннән алып өч эш көне эчендә муниципаль хезмәткәргә расписка белән тапшырыла. Әгәр муниципаль хезмәткәр күрсәтелгән расписканы бирүдән баш тартса, тиешле акт төзелә.

12. Муниципаль хезмәткәр җавапка тартуга карата федераль закон нигезендә шикаять бирә ала.

13. Әгәр җавапка тарту кулланылган көннән бер ел эчендә муниципаль хезмәткәр әлеге Кодексның 32 статьясындагы 1 өлешенең 1 яисә 2 пунктында каралган дисциплинар җавапка тартылмаса, ул җавапка тартылмаган дип санала.

14. Эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) муниципаль хезмәткәрдән әлеге Кодексның 32 статьясындагы 1 өлешенең 1 яисә 2 пунктында каралган дисциплинар җавапка тартуны, ул бирелгән көннән алып бер ел узганчы, үз инициативасы, муниципаль хезмәткәрнең язма гаризасы яисә аның турыдан-туры җитәкчесе үтенечe буенча кире алырга хокуклы.

8 бүлек. **Муниципаль берәмлектә кадрлар эше**

34 статья. **Муниципаль берәмлектә кадрлар эше**

Муниципаль берәмлектә кадрлар эшенә түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар составын булдыру;

2) муниципаль хезмәт турындагы законнарның нигезләмәләрен гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәр әзерләү һәм шул тәкъдимнәрне эшкә яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) кертү;

3) муниципаль хезмәткә урнашуга, аны узуга, хезмәт шартнамәсе (контракты) төзүгә, муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куюга, биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итүгә, муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттән җибәрелүенә һәм пенсиягә чыгуына бәйле муниципаль хокукый актлар проектларын әзерләүне оештыру һәм тиешле документларны рәсмиләштерү;

4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару;

5) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 30 статьясында билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси эшнамәләрен алып бару;

6) муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләрнең реестрын алып бару;

7) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт таныклыкларын рәсмиләштерү һәм тапшыру;

8) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү һәм муниципаль хезмәткәрләрне кадрлар резервына кертү;

9) муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләүне уздыру;

10) кадрлар резервы белән эшләүне һәм аннан нәтиҗәле файдалануны оештыру;

11) муниципаль хезмәткә кергәндә граждан тарафыннан бирелә торган шәхси белешмәләрнең һәм башка мәгълүматның дөреслеген тикшерүне оештыру, шулай ук дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга билгеләнгән рәвештәге рөхсәтне рәсмиләштерү;

12) муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне, шулай ук «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясында һәм башка федераль законнарда билгеләнгән муниципаль хезмәткә бәйле чикләүләрнең үтәлүен тикшерүне оештыру;

13) муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәтнең хокукый һәм башка мәсьәләләре буенча консультация бирү;

14) кадрлар эшенең хезмәт турындагы законнарда һәм әлеге Кодекста билгеләнә торган башка мәсьәләләрен хәл итү.

35 статья. **Муниципаль хезмәткәрнең шәхси белешмәләре**

1. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси белешмәләре – муниципаль хезмәтнең биләп торган вазыйфасы буенча бурычларны муниципаль хезмәткәрнең үтәвенә бәйле рәвештә эшкә яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) кирәкле һәм конкрет муниципаль хезмәткәргә кагылышлы булган мәгълүмат.

2. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси белешмәләре шәхси белешмәләр өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 14 бүлегендә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып эшкәртелергә тиеш.

36 статья. **Муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшнамәсен алып бару тәртибе**

1. Муниципаль хезмәткәргә шәхси эшнамә ачыла, моңа аның муниципаль хезмәткә урнашуы, аны узуы һәм муниципаль хезмәттән җибәрелүе белән бәйле документлар теркәп куела.

2. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшнамәсе 10 ел дәвамында саклана. Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәттән җибәрелгәндә, аның шәхси эшнамәсе муниципаль хезмәт узган соңгы урын буенча җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе архивында саклана.

3. Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торган җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бетерелгән очракта, аның шәхси эшнамәсе, саклау өчен, бетерелгән җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе функцияләре тапшырылган җирле үзидарә органына, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә, яисә аларның хокук варисларына тапшырыла.

4. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшнамәсен алып бару дәүләт граждан хезмәткәренең шәхси эшнамәсен алып бару өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

37 статья. **Муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләр реестры**

1. Муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләр реестры алып барыла.

2. Муниципаль хезмәттән җибәрелгән муниципаль хезмәткәр җибәрелү көнендә муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла.

3. Муниципаль хезмәткәр вафат булган (үлгән) йә законлы көченә кергән суд карары белән муниципаль хезмәткәр хәбәрсез югалган дип танылган яисә вафат булган дип игълан ителгән очракта, муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан ул вафат булган (үлгән) көннән соң яисә суд карары законлы көченә кергән көннән соң килә торган көндә төшереп калдырыла.

4. Муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе муниципаль хокукый акт белән раслана.

38 статья. **Муниципаль хезмәтнең кадрлар составын булдыруның өстенлекле юнәлешләре**

Муниципаль хезмәтнең кадрлар составын булдыруның өстенлекле юнәлешләре түбәндәгеләр була:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасына югары квалификацияле белгечләрне аларның профессиональ сыйфатларын һәм компетентлыгын исәпкә алып билгеләп кую;

2) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәттә үсүенә ярдәм итү;

3) муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү;

4) кадрлар резервын булдыру һәм аннан нәтиҗәле файдалану;

5) муниципаль хезмәткәрләрнең эш нәтиҗәләрен аттестация уздыру юлы белән бәяләү;

6) гражданнар муниципаль хезмәткә кергәндә, кадрлар сайлап алуның һәм аны узганда кадрлар белән эшләүнең заманча технологияләрен куллану.

39 статья. **Муниципаль хезмәттә кадрлар резервы**

Муниципаль берәмлекләрдә муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервы булдырылырга мөмкин.

9 бүлек. **Муниципаль хезмәтне финанслау һәм аны үстерү программалары**

40 статья. **Муниципаль хезмәтне финанслау**

Муниципаль хезмәтне финанслау җирле бюджетлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла, моңа муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү, пенсия тәэминаты чыгымнары, федераль законда яисә әлеге Кодекста башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль хезмәткәрләргә бирелә торган гарантияләрне тәэмин итүгә бәйле бүтән чыгымнар керә.

41 статья. **Муниципаль хезмәтне үстерү программалары**

1. Муниципаль хезмәтне үстерү җирле бюджетлар һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль хезмәтне үстерүнең муниципаль программалары һәм Татарстан Республикасының муниципаль хезмәтне үстерү программалары белән тәэмин ителә.

2. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең аерым органнарындагы муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, экспериментлар уздырылырга мөмкин. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән

муниципаль хезмәтне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышында экспериментлар уздыру тәртибе, шартлары һәм сроклары Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнә.

10 бүлек. **Йомгаклау һәм күчеш нигезләмәләре**

42 статья. **Күчеш нигезләмәләре**

1. Муниципаль хезмәткәрләргә бирелгән квалификация разрядлары муниципаль хезмәткәрләрнең әлеге Кодекста билгеләнгән классы чиннарына түбәндәге тәртиптә тиңләштерелә:

1, 2 яисә 3 нче классы гамәли муниципаль киңәшченең квалификация разряды тиешенчә 1, 2 яисә 3 нче классы гамәли муниципаль киңәшченең классы чинына тиңләштерелә;

1, 2 яисә 3 нче классы муниципаль киңәшченең квалификация разряды тиешенчә 1, 2 яисә 3 нче классы муниципаль киңәшченең классы чинына тиңләштерелә;

1, 2 яисә 3 нче классы муниципаль хезмәт киңәшчесенең квалификация разряды тиешенчә 1, 2 яисә 3 нче классы муниципаль хезмәт киңәшчесенең классы чинына тиңләштерелә;

1, 2 яисә 3 нче классы муниципаль хезмәт референтының квалификация разряды тиешенчә 1, 2 яисә 3 нче классы муниципаль хезмәт референтының классы чинына тиңләштерелә;

1, 2 яисә 3 нче классы муниципаль хезмәт секретареның квалификация разряды тиешенчә 1, 2 яисә 3 нче классы муниципаль хезмәт секретареның классы чинына тиңләштерелә.

2. Муниципаль хезмәткәрнең «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон үз көченә кергәннән соң муниципаль хезмәт вазыйфаларында эшләү чорлары, чираттагы класс чинын билгеләнгән тәртиптә бирү өчен, тиешле класс чинында булу чорына кертеп исәпләнә.

3. Муниципаль хезмәткәрләргә социаль гарантияләрне тәэмин итү максатларында, тиешле еллар эшләгән өчен пенсияне финанслау һәм түләү, аларны китереп бирүгә чыгымнарны да кертеп, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен пенсия белән тәэмин итү өчен каралган тәртиптә һәм шартларда башкарыла.

4. 2018 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль хокукый актларда авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре) вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләрендә аның урта һөнәри белеме булу каралган булырга мөмкин.

43 статья. **Әлеге Кодексның үз көченә керүе**

1. Әлеге Кодекс рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Кодексның 28 статьясының гамәлдә булу көче муниципаль хезмәт вазыйфаларын 2006 елның 1 гыйнварыннан биләгән затларга кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 25 июне
№ 50-ТРЗ

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры**

1 КИСӘК
**Муниципаль райондагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1 бүлек. **Вәкиллекле орган аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Аппарат җитәкчесе (эшләр идарәчесе).
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире).
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары;
мөстәкыйль сектор мөдире;
муниципаль район башлыгы ярдәмчесе;
муниципаль район башлыгы киңәшчесе;
мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең, секторның баш белгече;
бүлекнең, секторның әйдәүче белгече.
5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең, секторның 1 категорияле белгече;
бүлекнең, секторның 2 категорияле белгече;
бүлек, сектор белгече.

2 бүлек. **Башкарма комитеттагы, башкарма комитет аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Башкарма комитет җитәкчесе;
башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары;
башкарма комитет җитәкчесе урынбасары;
башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе).
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Идарә башлыгы;
мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире);
башка структур бүлекчә җитәкчесе.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары

Идарә башлыгы урынбасары;
мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары;
башка структур бүлекчә җитәкчесе урынбасары;
мөстәкыйль сектор мөдире;
башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе;
башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе;
идарә составындагы бүлек башлыгы;
идарә составындагы сектор мөдире;
мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең баш белгече;
идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең әйдәүче белгече.
5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең 1 категорияле белгече;
идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең 2 категорияле белгече;
идарә, бүлек, сектор, башка структур бүлекчә белгече.

3 бүлек. **Җирле үзидарәнең башка органындагы, җирле үзидарәнең башка органы аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе;
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире);
контроль-хисап органы аудиторы.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары;
мөстәкыйль сектор мөдире;
мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире;
контроль-хисап органы аппаратының баш инспекторы.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең, секторның баш белгече;
бүлекнең, секторның әйдәүче белгече;
контроль-хисап органы аппаратының әйдәүче инспекторы.
5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең, секторның 1 категорияле белгече;
бүлекнең, секторның 2 категорияле белгече;
бүлек, сектор белгече;
контроль-хисап органы аппараты инспекторы.

4 бүлек. **Сайлау комиссиясе аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире).
2. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең баш белгече;
бүлекнең әйдәүче белгече.
3. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең 1 категорияле белгече;
бүлекнең 2 категорияле белгече;
бүлек белгече.

II КИСӘК
**Шәһәр округындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

5 бүлек. **Вәкиллекле орган аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Аппарат җитәкчесе;
эшләр идарәчесе.
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Идарә башлыгы;
идарә башлыгының беренче урынбасары;
идарә башлыгы урынбасары;
мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире);
башка структур бүлекчә җитәкчесе;
мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары
Шәһәр округы башлыгы ярдәмчесе;
шәһәр округы башлыгы киңәшчесе.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Идарәнең, бүлекнең, башка структур бүлекчәнең баш белгече;
идарәнең, бүлекнең, башка структур бүлекчәнең әйдәүче белгече.
5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Идарәнең, бүлекнең, башка структур бүлекчәнең 1 категорияле белгече;
идарәнең, бүлекнең, башка структур бүлекчәнең 2 категорияле белгече;
идарә, бүлек, башка структур бүлекчә белгече.

6 бүлек. **Башкарма комитеттагы, башкарма комитет аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Башкарма комитет җитәкчесе;

башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары;
башкарма комитет җитәкчесе урынбасары;
башкарма комитет аппараты җитәкчесе;
район администрациясе башкарма комитеты башлыгы;
башкарма комитет территориясе префекты;
башкарма комитетның эшләр идарәчесе;
башкарма комитет аппараты җитәкчесе урынбасары;
башкарма комитетның эшләр идарәчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Идарә башлыгы;
башка структур бүлекчә җитәкчесе;
район администрациясе башкарма комитеты башлыгының беренче урынбасары;
идарә башлыгының беренче урынбасары;
башка структур бүлекчә җитәкчесенең беренче урынбасары;
идарә башлыгы урынбасары;
башка структур бүлекчә җитәкчесе урынбасары;
район администрациясе башкарма комитеты башлыгының урынбасары;
мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире);
район администрациясе башкарма комитеты аппараты җитәкчесе;
мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары
Мөстәкыйль сектор мөдире;
башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе;
башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе;
идарә составындагы бүлек, башка структур бүлекчә башлыгы;
идарә составындагы бүлек, башка структур бүлекчә башлыгы урынбасары;
район администрациясе башкарма комитеты бүлеге башлыгы;
идарә составындагы сектор, башка структур бүлекчә мөдире;
мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире;
район администрациясе башкарма комитеты бүлеге башлыгы урынбасары.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең баш белгече;
идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең әйдәүче белгече.
5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең 1 категорияле белгече;
идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең 2 категорияле белгече;
идарә, бүлек, сектор, башка структур бүлекчә белгече.

7 бүлек. **Җирле үзидарәнең башка органындагы, җирле үзидарәнең башка органы аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары

Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе;
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесенең беренче урынбасары;
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Идарә башлыгы;
идарә башлыгы урынбасары;
мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире);
мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары;
контроль-хисап органы аудиторы.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары
Мөстәкыйль сектор мөдире;
идарә составындагы бүлек башлыгы;
идарә составындагы сектор мөдире;
мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире;
контроль-хисап органы аппаратының баш инспекторы.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Идарәнең, бүлекнең, секторның баш белгече;
идарәнең, бүлекнең, секторның әйдәүче белгече;
контроль-хисап органы аппаратының әйдәүче инспекторы.
5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Идарәнең, бүлекнең, секторның 1 категорияле белгече;
идарәнең, бүлекнең, секторның 2 категорияле белгече;
идарә, бүлек, сектор белгече;
контроль-хисап органы аппараты инспекторы.

8 бүлек. **Сайлау комиссиясе аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире);
башка структур бүлекчә җитәкчесе;
мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары;
башка структур бүлекчә җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең, башка структур бүлекчәнең баш белгече;
бүлекнең, башка структур бүлекчәнең әйдәүче белгече.
3. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең, башка структур бүлекчәнең 1 категорияле белгече;
бүлекнең, башка структур бүлекчәнең 2 категорияле белгече;
бүлек, башка структур бүлекчә белгече.

# III КИСӘК

## Республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлегендәге муниципаль хезмәт вазыйфалары

9 бүлек. **Вәкиллекле орган аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Аппарат җитәкчесе (эшләр идарәчесе).
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире).
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары;
шәһәр җирлеге башлыгы ярдәмчесе;
шәһәр җирлеге башлыгы киңәшчесе.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең баш белгече;
бүлекнең әйдәүче белгече.
5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең 1 категорияле белгече;
бүлекнең 2 категорияле белгече;
бүлек белгече.

10 бүлек. **Башкарма комитеттагы, башкарма комитет аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Башкарма комитет җитәкчесе;
башкарма комитет җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе);
идарә башлыгы;
мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире);
башка структур бүлекчә җитәкчесе.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары
Идарә башлыгы урынбасары;
мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары;
башка структур бүлекчә җитәкчесе урынбасары;
мөстәкыйль сектор мөдире;
башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе;
башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе;
идарә составындагы бүлек башлыгы;
идарә составындагы сектор мөдире;
мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары

Идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең баш белгече;
идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең әйдәүче белгече.
5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең 1 категорияле белгече;
идарәнең, бүлекнең, секторның, башка структур бүлекчәнең 2 категорияле белгече;
идарә, бүлек, сектор, башка структур бүлекчә белгече.

11 бүлек. **Җирле үзидарәнең башка органындагы, җирле үзидарәнең башка органы аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе;
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире).
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары;
мөстәкыйль сектор мөдире;
мөстәкыйль бүлек составындагы сектор мөдире.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең, секторның әйдәүче белгече.
5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең, секторның 1 категорияле белгече;
бүлекнең, секторның 2 категорияле белгече;
бүлек, сектор белгече.

12 бүлек. **Сайлау комиссиясе аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире).
2. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең баш белгече;
бүлекнең әйдәүче белгече.
3. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең 1 категорияле белгече;
бүлекнең 2 категорияле белгече;
бүлек белгече.

# IV КИСӘК

## Район әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлегендәге муниципаль хезмәт вазыйфалары

13 бүлек. **Вәкиллекле орган аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Аппарат җитәкчесе (эшләр идарәчесе).
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире).
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең баш белгече;
бүлекнең әйдәүче белгече.
5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең 1 категорияле белгече;
бүлекнең 2 категорияле белгече;
бүлек белгече.

14 бүлек. **Башкарма комитеттагы, башкарма комитет аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Башкарма комитет җитәкчесе;
башкарма комитет җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе);
мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире);
башка структур бүлекчә җитәкчесе.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары;
башка структур бүлекчә җитәкчесе урынбасары.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең, башка структур бүлекчәнең баш белгече;
бүлекнең, башка структур бүлекчәнең әйдәүче белгече.
5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең, башка структур бүлекчәнең 1 категорияле белгече;
бүлекнең, башка структур бүлекчәнең 2 категорияле белгече;
бүлек, башка структур бүлекчә белгече.

15 бүлек. **Җирле үзидарәнең башка органындагы, җирле үзидарәнең башка органы аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе;
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире).
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең әйдәүче белгече.
5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең 1 категорияле белгече;
бүлекнең 2 категорияле белгече;
бүлек белгече.

16 бүлек. **Сайлау комиссиясе аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире).
2. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең баш белгече;
бүлекнең әйдәүче белгече.
3. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең 1 категорияле белгече;
бүлекнең 2 категорияле белгече;
бүлек белгече.

## V КИСӘК
## Шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегендәге муниципаль хезмәт вазыйфалары

17 бүлек. **Вәкиллекле орган аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире).
2. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең әйдәүче белгече.
3. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең 1 категорияле белгече;
бүлекнең 2 категорияле белгече;
бүлек белгече.

18 бүлек. **Башкарма комитеттагы, башкарма комитет аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Башкарма комитет җитәкчесе;
башкарма комитет җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире).
3. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең әйдәүче белгече.
4. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең 1 категорияле белгече;
бүлекнең 2 категорияле белгече;
бүлек белгече.

19 бүлек. **Җирле үзидарәнең башка органындагы, җирле үзидарәнең башка органы аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе;
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире).
3. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең әйдәүче белгече.
4. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең 1 категорияле белгече;
бүлекнең 2 категорияле белгече;
бүлек белгече.

20 бүлек. **Сайлау комиссиясе аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары
Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире).
2. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Бүлекнең әйдәүче белгече.
3. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
Бүлекнең 1 категорияле белгече;
бүлекнең 2 категорияле белгече;
бүлек белгече.

# VI КИСӘК

## Авыл җирлегендәге муниципаль хезмәт вазыйфалары

### 21 бүлек. **Вәкиллекле орган аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Әйдәүче белгеч.
2. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
1 категорияле белгеч;
2 категорияле белгеч;
белгеч.

### 22 бүлек. **Башкарма комитет аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
Башкарма комитет җитәкчесе;
башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (секретарь).
2. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Әйдәүче белгеч.
3. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
1 категорияле белгеч;
2 категорияле белгеч;
белгеч.

### 23 бүлек. **Сайлау комиссиясе аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары**

1. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары
Әйдәүче белгеч.
2. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары
1 категорияле белгеч;
2 категорияле белгеч;
белгеч.

Муниципаль хезмәт турында
Татарстан Республикасы кодексына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына муниципаль хезмәтнең түбәндәге вазыйфалары туры килә:

1) Татарстан Республикасы министрының беренче урынбасары вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;

муниципаль район, шәһәр округы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;

2) Татарстан Республикасы министры урынбасары вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге җирле үзидарәсенең башка органы җитәкчесе;

шәһәр округы җирле үзидарәсенең башка органы җитәкчесенең беренче урынбасары;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге җирле үзидарәсенең башка органы җитәкчесе урынбасары;

шәһәр округы башкарма комитетының район администрациясе башлыгы;

шәһәр округы башкарма комитетының территория префекты;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге вәкиллекле органы аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе);

муниципаль район башкарма комитеты аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе);

шәһәр округы вәкиллекле органы аппараты җитәкчесе, эшләр идарәчесе;

шәһәр округы башкарма комитеты аппараты җитәкчесе, эшләр идарәчесе;

3) Татарстан Республикасы министрлыгының эшләр идарәчесе вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

шәһәр округы башкарма комитетының район администрациясе башлыгының беренче урынбасары;

авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре);

4) Татарстан Республикасы министрлыгының департамент җитәкчесе вазыйфасына шәһәр округы башкарма комитеты аппараты җитәкчесе урынбасары, эшләр идарәчесе урынбасары вазыйфасы туры килә;

5) Татарстан Республикасы министрлыгының идарә башлыгы вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

шәһәр округы башкарма комитетының район администрациясе башлыгы урынбасары;

шәһәр округы башкарма комитеты, җирле үзидарәсенең башка органы идарәсе башлыгы;

шәһәр округы вәкиллекле органы аппараты, башкарма комитеты аппараты, җирле үзидарәсенең башка органы аппараты идарәсе башлыгы;

шәһәр округы вәкиллекле органы аппаратының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе;

шәһәр округы башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе;

шәһәр округы башкарма комитеты аппаратының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе;

шәһәр округы башкарма комитетының район администрациясе аппараты җитәкчесе;

республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты аппараты җитәкчесе (эшләр идарәчесе);

6) Татарстан Республикасы министрлыгының бүлек башлыгы вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты идарәсе башлыгы;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты аппараты идарәсе башлыгы;

шәһәр округы башкарма комитеты идарәсе башлыгының беренче урынбасары;

шәһәр округы вәкиллекле органы аппараты, башкарма комитеты аппараты идарәсе башлыгының беренче урынбасары;

шәһәр округы башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесенең беренче урынбасары;

шәһәр округы башкарма комитеты аппаратының башка структур бүлекчәсе җитәкчесенең беренче урынбасары;

шәһәр округы башкарма комитеты идарәсе башлыгы урынбасары;

шәһәр округы вәкиллекле органы аппараты, башкарма комитеты аппараты идарәсе башлыгы урынбасары;

шәһәр округы башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары;

шәһәр округы башкарма комитеты аппаратының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитетының, җирле үзидарәсе башка органының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире);

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге вәкиллекле органы аппаратының, башкарма комитеты аппаратының, җирле үзидарәсе башка органы аппаратының, сайлау комиссиясе аппаратының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире);

муниципаль районның, шәһәр округының контроль-хисап органы аудиторы;

7) Татарстан Республикасы министрлыгының бүлек башлыгы урынбасары вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

шәһәр округы җирле үзидарәсенең башка органы идарәсе башлыгы урынбасары;

шәһәр округы җирле үзидарәсенең башка органы аппараты идарәсе башлыгы урынбасары;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты идарәсе башлыгы урынбасары;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты аппараты идарәсе башлыгы урынбасары;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты аппаратының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе;

шәһәр округы башкарма комитетының, җирле үзидарәсе башка органының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) урынбасары;

шәһәр округы вәкиллекле органы аппаратының, башкарма комитеты аппаратының, җирле үзидарәсе башка органы аппаратының, сайлау комиссиясе аппаратының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) урынбасары;

шәһәр округы сайлау комиссиясе аппаратының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе;

8) Татарстан Республикасы министрлыгының сектор мөдире вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитетының, җирле үзидарәсе башка органының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) урынбасары;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге вәкиллекле органы аппаратының, башкарма комитеты аппаратының, җирле үзидарәсе башка органы аппаратының мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) урынбасары;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты аппаратының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары;

шәһәр округы сайлау комиссиясе аппаратының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары;

9) Татарстан Республикасы министры ярдәмчесе вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башлыгы ярдәмчесе;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе;

10) Татарстан Республикасы министры киңәшчесе вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башлыгы киңәшчесе;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе киңәшчесе;

11) Татарстан Республикасы министрлыгы департаменты идарәсе составындагы бүлек башлыгы вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

муниципаль район вәкиллекле органы аппаратының мөстәкыйль секторы мөдире;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитетының, җирле үзидарәсе башка органының мөстәкыйль секторы мөдире;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты аппаратының, җирле үзидарәсе башка органы аппаратының мөстәкыйль секторы мөдире;

шәһәр округы башкарма комитетының мөстәкыйль секторы мөдире;

шәһәр округы башкарма комитеты аппаратының мөстәкыйль секторы мөдире;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты идарәсе составындагы бүлек башлыгы;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты аппараты идарәсе составындагы бүлек башлыгы;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты идарәсе составындагы сектор мөдире;

муниципаль район, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты аппараты идарәсе составындагы сектор мөдире;

шәһәр округы башкарма комитеты идарәсе, башка структур бүлекчәсе составындагы бүлек башлыгы;

шәһәр округы башкарма комитеты аппараты идарәсе, башка структур бүлекчәсе составындагы бүлек башлыгы;

шәһәр округы җирле үзидарәсе башка органының мөстәкыйль секторы мөдире;

шәһәр округы җирле үзидарәсенең башка органы аппаратының мөстәкыйль секторы мөдире;

шәһәр округы җирле үзидарәсенең башка органы идарәсе составындагы бүлек башлыгы;

шәһәр округы җирле үзидарәсенең башка органы аппараты идарәсе составындагы бүлек башлыгы;

шәһәр округы башкарма комитетының район администрациясе бүлек башлыгы;

шәһәр округы башкарма комитеты идарәсе, башка структур бүлекчәсе составындагы бүлек башлыгы урынбасары;

шәһәр округы башкарма комитеты аппараты идарәсе, башка структур бүлекчәсе составындагы бүлек башлыгы урынбасары;

шәһәр округы башкарма комитеты идарәсе, башка структур бүлекчәсе составындагы сектор мөдире;

шәһәр округы башкарма комитеты аппараты идарәсе, башка структур бүлекчәсе составындагы сектор мөдире;

шәһәр округы җирле үзидарәсенең башка органы идарәсе составындагы сектор мөдире;

шәһәр округы җирле үзидарәсе башка органы аппараты идарәсе составындагы сектор мөдире;

12) әйдәүче киңәшче (әйдәүче консультант, әйдәүче белгеч) вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

муниципаль район вәкиллекле органы аппаратының мөстәкыйль бүлеге составындагы сектор мөдире;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитетының, җирле үзидарәсе башка органының мөстәкыйль бүлеге составындагы сектор мөдире;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты аппаратының, җирле үзидарәсе башка органы аппаратының мөстәкыйль бүлеге составындагы сектор мөдире;

шәһәр округы башкарма комитетының район администрациясе бүлеге башлыгы урынбасары;

муниципаль район, шәһәр округы контроль-хисап органы аппаратының баш инспекторы;

13) әйдәүче белгеч-эксперт вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты структур бүлекчәсенең баш белгече;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге вәкиллекле органы аппараты, башкарма комитеты аппараты, сайлау комиссиясе аппараты структур бүлекчәсенең баш белгече;

муниципаль район, шәһәр округы җирле үзидарәсе башка органы структур бүлекчәсенең баш белгече;

муниципаль район, шәһәр округы җирле үзидарәсе башка органы аппараты структур бүлекчәсенең баш белгече;

14) белгеч-эксперт (1 разрядлы өлкән белгеч) вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр

җирлеге башкарма комитеты, җирле үзидарәсенең башка органы структур бүлекчәсенең әйдәүче белгече;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге вәкиллекле органы аппараты, башкарма комитеты аппараты, җирле үзидарәсенең башка органы аппараты, сайлау комиссиясе аппараты структур бүлекчәсенең әйдәүче белгече;

муниципаль район, шәһәр округы контроль-хисап органы аппаратының әйдәүче инспекторы;

авыл җирлеге вәкиллекле органы аппаратының, башкарма комитеты аппаратының, сайлау комиссиясе аппаратының әйдәүче белгече;

15) 1 разрядлы белгеч вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты, җирле үзидарәсенең башка органы структур бүлекчәсенең 1 категорияле белгече;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге вәкиллекле органы аппараты, башкарма комитеты аппараты, җирле үзидарәсенең башка органы аппараты, сайлау комиссиясе аппараты структур бүлекчәсенең 1 категорияле белгече;

муниципаль район, шәһәр округы контроль-хисап органы аппараты инспекторы;

авыл җирлеге вәкиллекле органы аппаратының, башкарма комитеты аппаратының, сайлау комиссиясе аппаратының 1 категорияле белгече;

16) 2 разрядлы белгеч вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты, җирле үзидарәсенең башка органы структур бүлекчәсенең 2 категорияле белгече;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге вәкиллекле органы аппараты, башкарма комитеты аппараты, җирле үзидарәсенең башка органы аппараты, сайлау комиссиясе аппараты структур бүлекчәсенең 2 категорияле белгече;

авыл җирлеге вәкиллекле органы аппаратының, башкарма комитеты аппаратының, сайлау комиссиясе аппаратының 2 категорияле белгече;

17) 3 разрядлы белгеч вазыйфасына түбәндәге вазыйфалар туры килә:

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге башкарма комитеты, җирле үзидарәсенең башка органы структур бүлекчәсе белгече;

муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр (район әһәмиятендәге шәһәр яисә шәһәр тибындагы поселок) нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге вәкиллекле органы аппараты, башкарма комитеты аппараты, җирле

үзидарәсенең башка органы аппараты, сайлау комиссиясе аппараты структур бүлекчәсе белгече;

авыл җирлеге вәкиллекле органы аппараты, башкарма комитеты аппараты, сайлау комиссиясе аппараты белгече.

Муниципаль хезмәт турында
Татарстан Республикасы кодексына
3 нче кушымта

**Җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләнүче зат белән үрнәк контракт**

20__ елның "___ "__________ ____________

Бер яктан "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм муниципаль берәмлек уставы (алга таба – устав) нигезендә эш итүче муниципаль берәмлек башлыгы (алга таба – Башлык) һәм икенче яктан җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләнүче зат (алга таба – башкарма комитет җитәкчесе) түбәндәгеләр турында әлеге контрактны төзеделәр.

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге контракт законнар һәм устав нигезендә башкарма комитет җитәкчесе һәм җирле үзидарә органнары арасындагы хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм башка мөнәсәбәтләрне җайга сала, әлеге контракт якларының хокукларын һәм бурычларын билгели.

1.2. Башкарма комитет җитәкчесе законнарда, уставта һәм әлеге контрактта билгеләнгән шартларда әлеге контракт гамәлдә булган чорга башкарма комитет белән җитәкчелек итү буенча бурычларны үз өстенә ала.

2. Контрактның төп шартлары

2.1. Башкарма комитет җитәкчесе үз вазыйфасына конкурс нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнеп куела.

2.2. Башкарма комитет җитәкчесе муниципаль хезмәткәр була һәм башкарма комитетка җитәкчелек итә.

2.3. Башкарма комитет җитәкчесенең эшчәнлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм Башлык контролендә була, һәм ул аларга хисап тота.

2.4. Әлеге контракт буенча эш башкарма комитет җитәкчесе өчен төп эш булып санала.

2.5. Башка шартлар ______________________________________________________
_____________________________________________________________________________.

3. Башкарма комитет җитәкчесенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлешендә хокуклары һәм бурычлары

3.1. Башкарма комитет җитәкчесенең хокуклары һәм бурычлары законнар, устав, башка муниципаль хокукый актлар һәм әлеге контракт белән билгеләнә.

3.2. Башкарма комитет җитәкчесе:

3.2.1. берүзе баш булу принципларында җирле администрация (алга таба – башкарма комитет) эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм башкарма комитет компетенциясенә керә торган вәкаләтләрнең башкарма комитет тарафыннан үтәлеше өчен муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм Башлык каршында шәхсән җаваплы була;

3.2.2. муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, Башлык, җирле үзидарәнең, шул исәптән башка муниципаль берәмлекләрнең бүтән органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә башкарма комитет исеменнән эш йөртә;

3.2.3. муниципаль берәмлекнең комплекслы социаль-икътисадый үсеш планнарының һәм программаларының проектларын һәм аларның үтәлеше турындагы хисапларны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каравына кертә;

3.2.4. башкарма комитет структурасы проектын, башкарма комитет хезмәткәрләренең иң чик санын һәм аларның хезмәте өчен түләү фондын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы раславына кертә, хезмәткәрләрнең иң чик саны һәм хезмәт өчен түләү фонды белән билгеләнеп расланган структура нигезендә башкарма комитетның штат расписаниесен раслый;

3.2.5. башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын, башкарма комитет органнары җитәкчеләрен, Башлык белән килешеп, вазыйфаларына билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә, үз урынбасарлары арасындагы йөкләмәләрне бүлә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм башкарма комитетның башка хезмәткәрләрен вазыйфаларына билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга карата кызыксындыру чараларын һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана;

3.2.6. расланган бюджет нигезендә муниципаль берәмлек акчалары белән эш итә, законнар нигезендә муниципаль берәмлекнең бюджет счетларын һәм башка счетларын ача һәм яба;

3.2.7. үз эшчәнлегенең һәм башкарма комитет эшчәнлегенең нәтиҗәләре турында, шул исәптән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү хакында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына еллык хисаплар тапшыра;

3.2.8. башкарма комитет эшчәнлеге турында халыкка даими рәвештә мәгълүмат бирә, башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарны кабул итүне оештыра, айга кимендә бер мәртәбә гражданнарны шәхсән үзе кабул итә, гражданнар тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карый, алар буенча карарлар кабул итә;

3.2.9. дәүләт һәм башка органнарда муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын күрә, башкарма комитет исеменнән судка гаризалар бирә, ышанычнамәләр бирә;

3.2.10. законнар, устав, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарлары һәм әлеге контракт нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.3. Башкарма комитет җитәкчесе муниципаль берәмлек исеменнән мөлкәт хокукларын һәм башка хокукларны, бурычларны алырга һәм гамәлгә ашырырга, судта ышанычнамәсез эш итәргә хокуклы.

3.4. Башкарма комитет җитәкчесе федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, устав, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив хокукый актлары белән бирелгән вәкаләтләре кысаларында җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча, шулай ук башкарма комитет эшен оештыру мәсьәләләре буенча башкарма комитет күрсәтмәләрен чыгара.

3.5. Башка хокуклар ________________________________________________
________________________________________________________________________.

3.6. Башкарма комитет җитәкчесе түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

3.6.1. Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын, уставны һәм башка муниципаль хокукый актларны үтәргә, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм Башлык карарларын үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә;

3.6.2. гражданнар һәм оешмалар хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне һәм яклауны тәэмин итәргә;

3.6.3. Башлык, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, җирле үзидарәнең башка органнары белән хезмәттәшлек итүне законнарда, уставта, башка муниципаль хокукый актларда һәм әлеге контрактта билгеләнгән тәртиптә һәм рәвешләрдә гамәлгә ашырырга;

3.6.4. үз вазыйфаи бурычларын намус белән үтәргә;

3.6.5. үз хезмәт вазыйфаларын үтәү өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен тиешенчә тотарга;

3.6.6. дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне, шулай ук үз вәкаләтләрен үтәүгә бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган белешмәләрне, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә кагылышлы яисә аларның намусына һәм абруена кагылышлы белешмәләрне фаш итмәскә;

3.6.7. муниципаль хезмәткә бәйле тыюларны һәм чикләүләрне законнар нигезендә үтәргә;

3.6.8. билгеләнгән тәртиптә үзе һәм гаилә әгъзалары турында Россия Федерациясе законнарында каралган белешмәләр тапшырырга;

3.6.9. дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне, шул исәптән вәкаләтләрен үтәү өчен үзенә тапшырылган мөлкәтне сакларга.

3.7. Башкарма комитет җитәкчесе үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү очракларын булдырмаска тиеш.

Мәнфәгатьләр конфликты дигәндә, башкарма комитет җитәкчесенең шәхси кызыксынучанлыгы үз вазыйфаи бурычларын объектив үтәүгә тәэсир итә торган яисә тәэсир итәргә мөмкин булган һәм шуның аркасында башкарма комитет җитәкчесенең шәхси кызыксынучанлыгы һәм гражданнарның, оешмаларның, җәмгыятьнең, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекнең законлы мәнфәгатьләре арасында гражданнарның, оешмаларның, җәмгыятьнең, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекнең шул законлы мәнфәгатьләренә зыян китерергә мөмкин булган каршылык барлыкка китерә торган яисә барлыкка китерергә мөмкин булган вәзгыять дип аңларга кирәк.

Башкарма комитет җитәкчесенең шәхси кызыксынучанлыгы дигәндә, башкарма комитет җитәкчесенең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә акчалата йә натуралата керемнәр алу (нигезсез баю), турыдан-туры башкарма комитет җитәкчесе, аның гаилә әгъзалары һәм аның белән туганлыкта яисә әшнәлектә торучы башка затлар (ата-анасы, ире йә хатыны, балалары, ага-энеләре, апа-сеңелләре, шулай ук ире йә хатынының ага-энеләре, апа-сеңелләре, ата-анасы, балалары һәм балаларының ире йә хатыны) өчен, шулай ук башкарма комитет җитәкчесенә финанс яктан яисә башка йөкләмәләр буенча бәйле гражданнар яки оешмалар өчен матди яктан файдалы керемнәр алу мөмкинлеге дип аңларга кирәк.

Башкарма комитет җитәкчесендә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килгән очракта, башкарма комитет җитәкчесе бу хакта язма рәвештә Башлыкка хәбәр итәргә һәм мондый конфликтны булдырмый калдыру чараларын күрергә тиеш.

3.8. Башкарма комитет җитәкчесе законнарда, уставта, башка муниципаль хокукый актларда, әлеге контрактта билгеләнгән башка бурычларны үтәргә тиеш.

3.9. Башкарма комитет җитәкчесе үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрендә эш итәргә, үз хокукларын гамәлгә ашырырга һәм үз бурычларын намуслы һәм акыллы уйлап үтәргә тиеш.

3.10. Башка бурычлар______________________________________________
______________________________________________________________.

4. Башкарма комитет җитәкчесенең җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлештәге хокуклары һәм бурычлары

4.1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда башкарма комитет җитәкчесе түбәндәгеләрне үтәргә хокуклы:

4.1.1. җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен тапшыра торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән, шулай ук федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән очракларда федераль башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актлар белән билгеләнгән нигезләмәләр нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән шушы

вәкаләтләрне башкаруга бәйле мәсьәләләр буенча карарлар, шулай ук аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен үтәлеше кирәк булган башкарма комитет эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр бастырып чыгарырга;

4.1.2. җирле үзидарә органнарына федераль законнар белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны федераль башкарма хакимият органнарыннан, аларның территориаль органнарыннан соратып алырга;

4.1.3. җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан соратып алырга;

4.1.4. аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе турындагы, шулай ук аларның үтәлешен кирәкле матди ресурслар һәм финанс чаралары белән тәэмин итү турындагы тәкъдим белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына мөрәҗәгать итәргә;

4.1.5. үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен уставта каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалану турында вәкиллекле органга тәкъдимнәр кертергә;

4.1.6. аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча законнардагы таләпләрне бозуны бетерү турында вәкаләтле дәүләт органнары күрсәтмәләренә суд тәртибендә шикаять белдерергә;

4.1.7. аерым дәүләт вәкаләтләрен бирүне күздә тотучы федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән хокуклардан файдаланырга.

4.2. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда башкарма комитет җитәкчесе түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

4.2.1. аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен үтәлеше кирәк булган башкарма комитет эшен оештырырга;

4.2.2. аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен бирелгән матди ресурсларның һәм финанс чараларының, шулай ук шушы вәкаләтләрне башкару өчен уставта каралган очракларда һәм тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан өстәмә рәвештә файдаланыла торган үз матди ресурсларының һәм финанс чараларының сакланышын һәм алардан максатчан файдалануны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны үз вәкаләтләре кысаларында күрергә;

4.2.3. җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен тапшыра торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән нигезләмәләр нигезендә һәм шуларны үтәү йөзеннән чыгарылган муниципаль хокукый актлар турындагы белешмәләрне Россия Федерациясенең вәкаләтле дәүләт органнарына һәм (яисә) Татарстан Республикасының вәкаләтле дәүләт органнарына тапшырырга;

4.2.4. җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен тапшыра торган федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә шушы вәкаләтләрне башкару

турындагы хисапларны Россия Федерациясенең вәкаләтле дәүләт органнарына тапшырырга;

4.2.5. җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен тапшыра торган Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә шушы вәкаләтләрне башкару турындагы хисапларны Татарстан Республикасының вәкаләтле дәүләт органнарына тапшырырга;

4.2.6. федераль законнар белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаруны тикшереп торуда Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына ярдәм күрсәтергә;

4.2.7. Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаруны тикшереп торуда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына ярдәм күрсәтергә;

4.2.8. Россия Федерациясенең вәкаләтле дәүләт органнарының язма күрсәтмәләрендә җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан федераль законнар белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару мәсьәләләре буенча федераль законнар таләпләрен бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чараларны үз вәкаләтләре кысаларында күрергә;

4.2.9. Татарстан Республикасының вәкаләтле дәүләт органнарының язма күрсәтмәләрендә җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнары таләпләрен бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чараларны үз вәкаләтләре кысаларында күрергә;

4.2.10. аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен таләп ителә торган финанс чыгымнары исәп-хисапларын вәкаләтле дәүләт органнарына тапшырырга;

4.2.11. аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан башкаруны туктату турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән срокларда матди ресурсларны һәм файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтарырга;

4.2.12. аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнарына тапшыра торган федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән шартлар килеп туганда һәм тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан шушы вәкаләтләрне башкаруны туктатуга юнәлдерелгән чаралар күрергә.

## 5. Башлыкның хокуклары һәм бурычлары

5.1. Башлык түбәндәгеләргә хокуклы:

5.1.1. башкарма комитет җитәкчесеннән үз бурычларын башкарганда Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын, уставны, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм Башлык карарларын үтәвен таләп итәргә;

5.1.2. үз вәкаләтләре кысаларында башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан үтәлүе мәҗбүри булган йөкләмәләр бирергә;

5.1.3. башкарма комитет җитәкчесеннән Башлык, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле, шул исәптән башкарма комитет эшчәнлеген тикшереп торуга бәйле, сорала торган яисә башка килешенгән срокларда тапшырылырга тиешле бәяләмәләрне, документларны, белешмәне һәм башка мәгълүматны соратып алырга;

5.1.4. башкарма комитет җитәкчесенә карата законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә кызыксындыру чараларын кулланырга;

5.1.5. башкарма комитет җитәкчесен хезмәт вазыйфаларын үтәмәгән һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен законнар нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартырга;

5.1.6 башкарма комитет җитәкчесе җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлештә әлеге контракт шартларын бозуга бәйле рәвештә әлеге контрактны вакытыннан алда өзү турында судка мөрәҗәгать итәргә;

5.1.7. башка хокуклар ______________________________________________
_____________________________________________________________________.

5.2. Башлык башкарма комитет җитәкчесенең законнарда, муниципаль хокукый актларда һәм әлеге контрактта каралган хокукларын һәм гарантияләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү чараларын күрә.

5.3. Федераль законнар һәм башка норматив хокукый актлар белән вәкаләт бирелгән органнар һәм вазыйфаи затлар таләпләре буенча һәм законнарда каралган башка очракларда вазыйфаи бурычларын үтәү өчен медицина бәяләмәсе нигезендә каршы күрсәткечләр булуы ачыкланган очракта, Башлык башкарма комитет җитәкчесен били торган вазыйфасыннан читләштерергә (вазыйфаи бурычларын үтәүне тыярга) тиеш.

5.4. Башкарма комитет җитәкчесе һәм башкарма комитет органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча Башлыкның бүтән вәкаләтләре законнар, устав һәм башка муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

6. Башкарма комитет җитәкчесенә хезмәт өчен түләү һәм аның эш вакыты режимы

6.1. Башкарма комитет җитәкчесенә гамәлдәге законнар һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый актлары нигезендә акчалата вазыйфаи тулы керем түләнә.

6.2. Башкарма комитет җитәкчесенең вазыйфаи окладыкүләме, инфляция дәрәҗәсен (куллану бәяләрен) исәпкә алып, тиешле елга муниципаль берәмлек бюджеты нигезендә ел саен арттырыла (индексацияләнә). Вазыйфаи оклад күләмен арттыру (индексацияләү) турында карар Башлык тарафыннан кабул ителә.

6.3. Башкарма комитет җитәкчесе үз эшчәнлеген нормага салынмаган хезмәт көне шартларында гамәлгә ашыра.

7. Башкарма комитет җитәкчесенең үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның социаль-көнкүреш һәм башка шартлары

7.1. Җирле бюджет акчалары исәбеннән хезмәт вазыйфаларын башкару өчен башкарма комитет җитәкчесенә тәүлек буе эшләүче машина йөртүче белән хезмәт автомашинасы, мобиль элемтә чаралары бирелә.

7.2. Башкарма комитет җитәкчесенә командировка чыгымнары түләнә, бүтән түләүләр башкарыла, шулай ук ел саен түләүле отпуск бирелә һәм законнарда, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив хокукый актларында муниципаль хезмәткәрләр, Башлык өчен билгеләнгән башка гарантияләр бирелә.

7.3. Башка шартлар______________________________________________________________________________________.

8. Башкарма комитет җитәкчесенең вәкаләтләре чоры

8.1. Башкарма комитет җитәкчесе үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга әлеге контракт төзелгән көннән керешә.

Бу контракт затны башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына билгеләп кую турында карар кабул иткән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре чорына (яңа чакырылыш муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы эше башланган көнгә кадәр) төзелә һәм ______ тәшкил итә.

8.2. Башкарма комитет җитәкчесенең вәкаләтләре вакытыннан алда түбәндәге очракларда туктатыла:

8.2.1. вафат булганда;

8.2.2. үз теләге белән отставкага киткәндә;

8.2.3. әлеге контрактны законда билгеләнгән тәртиптә өзгәндә;

8.2.4. "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфасыннан баш тартканда;

8.2.5. суд тарафыннан хокукый сәләтсез яки хокукый сәләте чикле дип танылганда;

8.2.6. суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылганда яисә вафат дип игълан ителгәндә;

8.2.7. аңа карата судның гаепләү карары закон көченә кергәндә;

8.2.8. даими яшәү өчен Россия Федерациясеннән читкә киткәндә;

8.2.9. Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда, чит дәүләт гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгы туктатылганда, муниципаль хезмәткәр чит дәүләт гражданлыгын алганда яки чит дәүләт гражданлыгына ия Россия Федерациясе гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашмаган чит дәүләт территориясендә Россия Федерациясе гражданының яшәүгә рөхсәт яисә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алганда;

8.2.10. хәрби хезмәткә чакырылганда яисә аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә җибәрелгәндә;

8.2.11. "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 13 статьясындагы 3, 4 – 7 өлешләре нигезендә муниципаль берәмлек үзгәртеп корылганда, шулай ук муниципаль берәмлек бетерелгән очракта;

8.2.12. җирлек шәһәр округына кушылуга бәйле рәвештә муниципаль берәмлек статусын югалтканда;

8.2.13. муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү яисә җирлекне шәһәр округына кушу нәтиҗәсендә муниципаль берәмлек сайлаучылары саны 25 проценттан да күбрәккә артканда;

8.2.14. башкарма комитет җитәкчесе вәкаләтләрен башкаручы Башлык вазыйфага керешкәндә.

8.3. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре чоры узгач йә аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда, башкарма комитет җитәкчесе үз вәкаләтләрен башкарма комитетның билгеләнгән тәртиптә яңа җитәкчесе билгеләнеп куелганчы һәм аның белән контракт төзелгәнче дәвам итә.

9. Якларның җаваплылыгы

9.1. Әлеге контракт шартларын үтәмәгән һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен яклар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы була.

9.2. Башкарма комитет җитәкчесе аның гаебе белән муниципаль берәмлеккә, башкарма комитетка китерелгән зыян өчен тулысынча матди җаваплы була. Әлеге җаваплылык тиешле суд карары нигезендә йөкләнә.

9.3. Башкарма комитет җитәкчесе җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен шул максатларга муниципаль берәмлеккә бүлеп бирелгән матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен федераль законнар нигезендә җаваплы була.

9.4. Башлык мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу чорында башкарма комитет җитәкчесен биләгән вазыйфасыннан читләштерергә (вазыйфаи бурычларын үтәүне тыярга) хокуклы. Мондый очракта башкарма комитет җитәкчесенең биләгән вазыйфасыннан читләштерелгән вакытка акчалата вазыйфаи тулы кереме сакланып кала.

9.5. Башка шартлар ______________________________________________
_______________________________________________________________.

10. Контрактны үзгәртү һәм өзү. Бәхәсләрне хәл итү

10.1. Якларның һәркайсы икенче як каршында әлеге контрактны үзгәртү (төгәлләштерү) яисә аңа өстәмә кертү турындагы мәсьәләне куярга хокуклы, алар өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә, ул муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланганнан соң контрактка теркәлә.

10.2. Башкарма комитет җитәкчесе белән контракт яклар килешүе буенча яисә түбәндәгеләрнең гаризасы нигезендә суд тәртибендә вакытыннан алда өзелергә мөмкин:

10.2.1. муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының яисә Башлыкның – контракт шартларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлешендәге бозуларга бәйле, шулай ук федераль законда каралган башка очракларда;

10.2.2. Татарстан Республикасы Президентының – контракт шартларын федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендәге бозуларга бәйле;

10.2.3. башкарма комитет җитәкчесенең – контракт шартларын җирле үзидарә органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан бозуларга бәйле.

10.3. Яклар килешүен күздә тота торган очракларда контрактны вакытыннан алда өзү турындагы тәкъдим икенче якка контрактны туктатуның күздә тотыла торган вакытына кадәр ике айдан да соңга калмыйча язма рәвештә җибәрелергә тиеш.

10.4. Яклар арасындагы бәхәсләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

11. Контрактның гамәлдә булу чоры

11.1. Әлеге контрактның 8.1 пункты нигезендә башкарма комитет җитәкчесенең вәкаләтләре чоры узганнан соң, әлеге контракт билгеләнгән тәртиптә яңа башкарма комитет җитәкчесе билгеләнеп куелганчыга һәм аның белән контракт төзелгәнчегә кадәр гамәлдә була. Башкарма комитетның яңа җитәкчесе белән контракт төзелгән көннән әлеге контрактның гамәлдә булуы туктатыла һәм башкарма комитет белән җитәкчелек итү вәкаләтләре башкарма комитетның яңа җитәкчесенә күчә.

11.2. Башкарма комитет җитәкчесе белән төзелгән контракт аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә аның вәкаләтләре чоры дәвамында гамәлдә була, әмма, аерым дәүләт вәкаләтләренең гамәлдә булуы аерым вакыт белән билгеләнгән булса, шул вәкаләтләр гамәлдә булган чордан озаграк була алмый.

11.3. Әлеге контрактның гамәлдә булуы вакытыннан алда (әлеге контрактның 11.1 пунктында билгеләнгән вакыттан алдарак) законнар һәм шушы контрактның 8.2 пункты нигезендә башкарма комитет җитәкчесенең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән туктатыла.

12. Йомгаклау нигезләмәләре

12.1. Әлеге контракт яклар имза салган көненнән үз көченә керә.

12.2. Вәкаләтләр чоры узгач йә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылса, башкарма комитет җитәкчесе кабул итү-тапшыру акты буенча барлык мөһерләрне, штампларны, финанс документларын һәм үзендәге барлык башка документларны, сейф ачкычларын башкарма комитетның яңа билгеләнеп куелган җитәкчесенә йә аның вазыйфаларын вакытлыча башкаручы затка тапшырырга тиеш.

12.3. Контракт бер үк юридик көчкә ия булган өч нөсхәдә төзелде, бер нөсхә – башкарма комитетның кадрлар хезмәтендә (башкарма комитет җитәкчесенең шәхси эш папкасында), бер нөсхә – Башлыкта, бер нөсхә башкарма комитет җитәкчесендә саклана.

Якларның имзалары һәм реквизитлары:

| | |
|---|---|
| Башлык ____________________<br>______________________________<br><br><br><br><br>______________________________<br>(имза) (Ф.И.Ат.ис.) | Башкарма комитет җитәкчесе<br>______________________________<br>Паспорт<br>белешмәләре:_______________<br>Адрес: ____________________<br>______________________________<br>______________________________<br>(имза) (Ф.И.Ат.ис.) |

Муниципаль хезмәт турында
Татарстан Республикасы кодексына
4 нче кушымта

**Муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү турында үрнәк нигезләмә**

1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Әлеге Үрнәк нигезләмә белән җирле үзидарә органнарында, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләрендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрүнең гомуми тәртибе билгеләнә.

2. Аттестация муниципаль хезмәткәрнең профессиональ эшчәнлеген бәяләү нигезендә били торган муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килүен билгеләү максатларында үткәрелә.

Аттестация муниципаль хезмәтнең кадрлар составын төзүгә, муниципаль хезмәткәрләрнең профессиональ дәрәҗәсен күтәрүгә, җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә муниципаль хезмәт вазыйфалары кыскартылганда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә өстенлекле хокукны ачыклауга бәйле мәсьәләләрне, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартларын үзгәртүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүгә ярдәм итәргә тиеш.

3. Түбәндәге муниципаль хезмәткәрләр аттестацияләнми:

1) били торган муниципаль хезмәт вазыйфасында бер елдан ким эшләгән;

2) 60 яшькә җиткән;

3) йөкле хатыннар;

4) йөклелек һәм бала табу яисә бала карау буенча отпусктагы муниципаль хезмәткәр баласына өч яшь тулганчы. Күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрләргә отпусктан чыккач кимендә бер елдан соң гына аттестация үткәрелергә мөмкин;

5) вакытлы хезмәт шартнамәсе (контракты) нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүчеләр.

4. Муниципаль хезмәткәргә аттестация өч елга бер тапкыр үткәрелә.

2 бүлек. **Аттестация үткәрүне оештыру**

5. Муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү өчен яллаучы вәкиле (эш бирүче) карары буенча җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең хокукый акты чыгарыла, анда түбәндәге нигезләмәләр була:

1) аттестация комиссиясен төзү турында;

2) аттестация үткәрү графигын раслау турында;

3) аттестацияләнергә тиеш муниципаль хезмәткәрләрнең исемлекләрен төзү турында;

4) аттестация комиссиясе эше өчен кирәкле документлар әзерләү турында.

6. Аттестация комиссиясе җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең хокукый акты белән төзелә. Әлеге актта аттестация комиссиясенең составы, аның эшләү сроклары һәм тәртибе билгеләнә.

Аттестация комиссиясе составына яллаучы вәкиле (эш бирүче) һәм (яисә) ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәдән һәм юридик (хокукый) бүлекчәдән, муниципаль хезмәткәр аттестацияләнергә тиешле һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче бүлекчәдән), шулай ук муниципаль хезмәткә бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез экспертлар-белгечләр буларак персональ белешмәләрен күрсәтмичә генә чакырылучы фән һәм мәгариф учреждениеләре, башка оешмалар вәкилләре керә. Бәйсез экспертларның саны аттестация комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Вазыйфаи бурычларны үтәүләре дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү өчен аттестация комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

Аттестация комиссиясе составы аттестация комиссиясе кабул итә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликтларын барлыкка китерү мөмкинлеге барлыкка килмәслек итеп төзелергә тиеш.

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары үзенчәлегеннән чыгып, җирле үзидарә органында берничә аттестация комиссиясе төзелергә мөмкин.

7. Аттестация комиссиясен комиссиянең рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары тәшкил итә. Карарлар кабул иткәндә аттестация комиссиясенең барлык әгъзалары бертигез хокукларга ия була.

8. Аттестация үткәрү графигы ел саен яллаучы вәкиле (эш бирүче) тарафыннан раслана һәм аттестацияләнә торган һәр муниципаль хезмәткәргә аттестация башланырга кимендә бер ай кала хәбәр ителә.

9. Аттестация үткәрү графигында түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) аттестация үткәрелә торган җирле үзидарә органы, бүлекчәсе исеме;

2) аттестацияләнергә тиеш муниципаль хезмәткәрләр исемлеге;

3) аттестация үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

4) җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратының тиешле бүлекчәләренең кирәкле документларны тапшыру өчен җаваплы җитәкчеләре күрсәтелеп, аларны аттестация комиссиясенә тапшыру датасы.

10. Аттестация башланырга ике атнадан да соңга калмыйча, аттестация комиссиясенә аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәрнең аттестация чорында үз вазыйфаи бурычларын башкаруы турында турыдан-туры җитәкчесе имза салган һәм югарырак җитәкче тарафыннан расланган бәя бирелә.

11. Әлеге Үрнәк нигезләмәнең 10 пунктында каралган бәядә муниципаль хезмәткәр турында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

б) аттестация үткәрү вакытына били торган муниципаль хезмәт вазыйфасы һәм шушы вазыйфага билгеләнеп кую датасы;

в) муниципаль хезмәткәр хәл итүдә (эшләүдә) катнашкан төп мәсьәләләр (документлар) исемлеге;

г) муниципаль хезмәткәрнең профессиональ, шәхси сыйфатларының һәм профессиональ эшчәнлеге нәтиҗәләренең дәлилләнгән бәяләмәсе.

12. Аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәрнең аттестация чорында үз вазыйфаи бурычларын башкару турындагы бәясенә муниципаль хезмәткәр тарафыннан башкарылган йөкләмәләр һәм күрсәтелгән чорда муниципаль хезмәткәрнең профессиональ эшчәнлеге турында еллык хисаплардагы ул әзерләгән документ проектлары турында белешмәләр кушып бирелә.

Киләсе һәр аттестация вакытында аттестация комиссиясенә элеккеге аттестация белешмәләре белән муниципаль хезмәткәрнең аттестация язуы тәкъдим ителә.

13. Җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе аттестация башланырга кимендә биш эш көне кала аттестацияләнә торган һәр муниципаль хезмәткәрне аттестация чорында аның вазыйфаи бурычларын башкаруы турында бирелгән бәясе белән таныштырырга тиеш. Бу чакта аттестацияләнә торган муниципаль хезмәткәр аттестация комиссиясенә күрсәтелгән чорда үзенең профессиональ эшчәнлеге турында өстәмә белешмәләр бирергә, шулай ук бирелгән бәя белән ризалашмавы турында гариза яисә турыдан-туры җитәкчесенең бәясенә карата аңлатма язуы бирергә хокуклы.

3 бүлек. **Аттестация үткәрү**

14. Аттестация аттестация комиссиясе утырышына аттестацияләнә торган муниципаль хезмәткәрне чакырып үткәрелә. Муниципаль хезмәткәр әлеге комиссия утырышына нигезсез сәбәп аркасында килмәгән очракта яисә аттестациядән баш тартса, муниципаль хезмәт турындагы законнар нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартыла, ә аттестация соңрак вакытка күчерелә.

Аттестация комиссиясе тапшырылган документларны карый, аттестацияләнә торган муниципаль хезмәткәрнең һәм, кирәк булганда, аның турыдан-туры җитәкчесенең муниципаль хезмәткәрнең профессиональ хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматын тыңлый. Аттестацияне объектив үткәрү максатларында аттестация комиссиясе аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәр тарафыннан аттестация чорында үзенең профессиональ эшчәнлеге турында бирелгән өстәмә белешмәләрне караганнан соң аттестацияне комиссиянең киләсе утырышына күчерергә хокуклы.

15. Муниципаль хезмәткәрнең профессиональ эшчәнлегенә карата профессиональ һәм шәхси сыйфатлары турында фикер алышу объектив һәм кешелекле мөнәсәбәттә булырга тиеш.

Муниципаль хезмәткәрнең профессиональ эшчәнлеге аның үзе били торган муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфасы буенча квалификация таләпләренә туры килүен, тиешле бүлекчә (җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты) алдында куелган бурычларны хәл итүдә катнашуын,

ул башкара торган эшнең катлаулылыгын, файдалы булуын һәм нәтиҗәлелеген билгеләү нигезендә бәяләнә.

Бу чакта муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкцияне үтәү нәтиҗәләре, профессиональ белемнәре, муниципаль хезмәткәр эшендәге тәҗрибәсе, муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәве, тыелган тәртип бозулар булмавы, хезмәт тәртибе таләпләрен һәм йөкләмәләрен үтәве, ә башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәрне аттестацияләгәндә шулай ук оештыру сәләтләре исәпкә алынырга тиеш.

16. Аттестация комиссиясе утырышы, анда комиссия әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы булып санала.

17. Аттестация комиссиясе карары, аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәр һәм аның турыдан-туры җитәкчесе булмаганда, утырышта катнашучы аттестация комиссиясе әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү нигезендә кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, муниципаль хезмәткәр били торган муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә дип таныла.

Аттестация комиссиясе әгъзасы булып торучы муниципаль хезмәткәрне аттестацияләгән вакытта аның әлеге комиссиядә әгъза булуы туктатып торыла.

18. Муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү нәтиҗәләре буенча аттестация комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) били торган муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә;

2) били торган муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә һәм вазыйфаи үсеш тәртибендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән тәртиптә кадрлар резервына кертелүгә тәкъдим ителә;

3) яңадан профессиональ әзерлекне уңышлы узу яисә квалификация күтәрү шарты белән били торган муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә;

4) били торган муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килми.

19. Аттестация нәтиҗәләре тавыш бирүгә йомгак ясалганнан соң аттестацияләнгән муниципаль хезмәткәрләргә турыдан-туры хәбәр ителә.

Аттестация нәтиҗәләре кушымта нигезендәге рәвеш буенча муниципаль хезмәткәрнең аттестация язуына кертелә. Аттестация язуына аттестация комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм утырышта булган аттестация комиссиясе әгъзалары имза сала.

Муниципаль хезмәткәр, имза салып, аттестация язуы белән таныша.

Аттестация узган муниципаль хезмәткәрнең аттестация язуы һәм аттестация чорында аның ул вазыйфаи бурычларын үтәве турындагы бәя муниципаль хезмәткәрнең шәхси эш папкасында саклана.

Аттестация комиссиясе секретаре комиссия утырышы беркетмәсен алып бара, анда комиссиянең карары һәм тавыш бирү нәтиҗәләре күрсәтелә. Аттестация комиссиясе утырышы беркетмәсенә аттестация комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре, утырышта булган аттестация комиссиясе әгъзалары имза сала.

20. Муниципаль хезмәткәрләрнең аттестация материаллары, аны үткәргәннән соң җиде көннән дә соңга калмыйча, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) тапшырыла.

21. Аттестация үткәрелгәннән соң бер ай дәвамында аның нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең

хокукый акты чыгарыла яисә яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) карары кабул ителә, аның буенча муниципаль хезмәткәр:

1) билгеләнгән тәртиптә вазыйфаи үсеш тәртибендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен кадрлар резервына кертелә;

2) яңадан профессиональ әзерлек узуга яисә квалификация күтәрүгә җибәрелә;

3) муниципаль хезмәт вазыйфасында түбәнәя.

22. Муниципаль хезмәткәр яңадан профессиональ әзерлек узудан, квалификация күтәрүдән яисә муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчүдән баш тартса, яллаучы вәкиле (эш бирүче) муниципаль хезмәт турындагы законнар нигезендә муниципаль хезмәткәрне били торган муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итәргә һәм муниципаль хезмәттән җибәрергә хокуклы.

Аттестация үткәрелгәннән соң бер ай узгач, әлеге аттестация нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчерү йә муниципаль хезмәттән азат итүгә юл куелмый. Муниципаль хезмәткәрнең күрсәтелгән чорда авырган вакыты һәм ел саен түләнә торган отпуск вакыты исәпкә алынмый.

23. Муниципаль хезмәткәр аттестация нәтиҗәләренә Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү турындагы Үрнәк нигезләмәгә кушымта

**МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРНЕҢ**

**АТТЕСТАЦИЯ КӘГАЗЕ**

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме ______________________________

______________________________________________________________

2. Туган елы, көне, ае ____________________________________________

3. Профессиональ белеме, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме турында белешмәләр__________________________________________________

(кайчан һәм кайсы уку йортын тәмамлаган, белеме буенча

______________________________________________________________

белгечлеге һәм квалификациясе, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме

______________________________________________________________

______________________________________________________________

4. Аттестация вакытына били торган муниципаль хезмәт вазыйфасы һәм әлеге вазыйфага билгеләнеп кую датасы

______________________________________________________________

5. Муниципаль хезмәт стажы (шул исәптән дәүләт граждан хезмәте стажы)

______________________________________________________________

6. Гомуми хезмәт стажы _____________________________________

______________________________________________________________

7. Муниципаль хезмәткәргә сораулар һәм аларга кыскача җаваплар_____________________________________________________

______________________________________________________________

8. Аттестация комиссиясе тарафыннан әйтелгән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

9. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан элеккеге аттестациядәге рекомендацияләр үтәлешен кыскача бәяләү

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(үтәлгән, өлешчә үтәлгән, үтәлмәгән)

10. Аттестация комиссиясе карары

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(үзе били торган муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә; үзе били торган муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә һәм вазыйфаи үсеш тәртибендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән тәртиптә кадрлар резервына кертелүгә тәкъдим ителә; яңадан профессиональ әзерлекне уңышлы узу һәм квалификация күтәрү шарты белән үзе били торган муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә; үзе били торган муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килми)

11. Аттестация комиссиясенең санлы составы ________________________

Утырышта аттестация комиссиясенең _____________ әгъзасы катнашты.

Хуплап бирелгән тавышлар саны _______, каршы бирелгән тавышлар саны ________.

12. Искәрмәләр __________________________________________________

______________________________________________________________________

Аттестация комиссиясе рәисе___________ _________________________

(имза) (тулы имза)

Аттестация комиссиясе рәисе урынбасары ______ _________________

(имза) (тулы имза)

Аттестация комиссиясе секретаре _______ ____________________

(имза) (тулы имза)

Аттестация комиссиясе әгъзалары_______________________________

(имза) (тулы имза)

Аттестация үткәрү датасы

____________________________

Аттестация язуы белән таныште ________________________________

(муниципаль хезмәткәр имзасы, дата)

Мөһер өчен урын
(җирле үзидарә органы, муниципаль
берәмлекнең сайлау комиссиясе)